Илгә эшчеләр кирәк – 2

Авыл хуҗалыгы белгечләрен кайда әзерлиләр?

Абитуриентларга ярдәмгә уку йортларын барлауны дәвам итәбез. Бүген без авыл хуҗалыгы тармагында белгечләр әзерли торган уку йортларына тукталдык.

6-7 БИТ

«Әти хакы» бәйгесе җиңүчеләре

Велосипедлар кемгә эләкте?

10-11 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Пәнҗешәмбе | 8.06.2017 | № 61 (5823)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

БЕЗДӘН НИНДИ ТАШЛАМАЛАРНЫ ЯШЕРӘЛӘР?

Безнең илдә тиеш булган ташламалар да, матди ярдәм төрләре дә шактый, әмма күпләребез алар турында белеп кенә бетерми. Җаваплы кешеләр әйтеп-аңлатып торуны кирәксенми, ә халык рәсми документларны тикшерергә иренә, хәтта билгеле бер төр ташламалар барлыгы турында башына да китерми. Халык күзеннән һәм колагыннан бераз читтәрәк калган, әмма һичшиксез тиеш булган ташламалар турында тәфсилләбрәк аңлатабыз.

5 БИТ

fb.ru

ПЕНСИЯДӘГЕ ФАХИШӘ МОНОЛОГЫ

12 БИТ

МӘХӘББӘТ АЯККА БАСАРГА ЯРДӘМ ИТКӘН

12 БИТ

РЕСПУБЛИКАДА

АЗНАКАЙ

Рузилә һәм Нил Нигъмәтуллиннарның гаиләсендә зур сөенеч: беренче балалары – өч малайлары туган. Әти-әниләре игезәкләргә Кәрим, Камил һәм Шамил дип исем кушкан. Азнакай районы башлыгы Марсель Шәйдуллин, Нигъмәтуллиннар гаиләсенең шатлыгын уртаклашып, бүләкләр тапшырган.

ӘЛКИ

Район советы утырышында Сихтермә-Хузангай авылы исемен Иске Сихтермә дип үзгәртү мәсьәләсен күтәргәннәр. Петр Хузангай – Сихтермә авылында туган чуваш шагыйре. Авылның атамасын да аның хөрмәтенә үзгәрткән булганнар. Хәзер халык борынгыдан килгән Иске Сихтермә исемен кире кайтырырга тели. Авыл җирлеге советының, халыкның әлеге инициативасы Татарстан Дәүләт Советына тәкъдим ителгән.

БАЛТАЧ

Балтачта «Бала арбалары парады» бәйгесе игълан ителде. Конкурста биш яшьтән кечерәк баласы булган һәркем катнаша ала. «Коляскалар парады» конкурсантларына бәби арбаларын бизәп килергә кирәк. Темалар төрле: «Милли төсмер»,«Галәм дөньясы», «Мультик вакыйгалары» һәм башкалар. Иң үзенчәлекле бала арбасы хуҗасын 28 июньдә билгеләячәкләр.

МИНЗӘЛӘ

Каран-Азик авылында яшәүче Михаил Шатунов авылны яшелләндерергә булган. Ул авыл кырыендагы кырга 300 төп чыршы утырткан. Бу эштә аңа гаиләсе дә булышкан.

ЧҮПРӘЛЕ

Район үзәгендә яшәүче Хәйретдиновлар гаиләсе үз хуҗалыкларында «Аллаһ» сүзе «язылган» тавык йомыркасын тапкан. Районның «Җәмигъ» мәчете хәзрәтләре дә йомыркадан «Аллаһ» сүзен укыган. «Ни генә булмасын, бу – Ходай Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә ишарә. Бигрәк тә Рамазан аенда районда мондый уникаль очрак изге гамәлләрдән санала», – дигән район мөхтәсибе Рөстәм хәзрәт Рәкыйпов.

Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды

ҖӘЙГЕ КҮЧТӘНӘЧ

Июнь китергән яңалыклар

Дамир Бәдриев фотосы

БӘЯЛӘР

3 июньнән «Россия почтасы» хезмәтләре 25 процентка кыйммәтләнде. 20 граммга кадәр гади хатны почта аша җибәрү өчен элек 19 сум түләргә кирәк булса, хәзер ул 22 сум тора. Заказ белән юллана торган хат бәясе 37 сумнан 41 сумга, «кыйммәтле» хат 90 сумнан 95 сумга арткан. Гади бандероль җибәрү дә 40 сумга төшәчәк.

Җәйдән гомумйорт ихтыяҗлары өчен чыгымнарны каплауга тотылган түләүләр яңа тәртип буенча исәпләнәчәк. Димәк, торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрдә үзгәрешләр булачак дигән сүз. Июнь аендагы үзгәрешләрне июльдә киләчәк квитанцияләрдә сизәрбез. Закон нигезендә, йортның гомуми ихтыяҗы дигән төшенчәгә торактагы бөтен кеше файдалана торган подъездларны яктырту, газоннарны сугару һәм башкалар керә.

Яңа кагыйдәләр нигезендә, гомуми ихтыяҗлар, коммуналь хезмәтләр исемлегеннән алынып, торак хезмәтләр графасына күчереләчәк. Урын алыштырудан сумма үзгәрмәсә дә, яңа кагыйдәнең отышлы яклары бар. Әйтик, ОДН өчен түләгәндә, элек норматив күрсәткечләр белән фатирлардагы исәпләгеч җайланмалар күрсәткечләре арасындагы аерманы исәпләп, шул сумманы счетчик куйдырмаган фатир хуҗаларына бүлеп түләттерәләр иде. Хәзер исә норматив күрсәткечләр генә фатирлар арасында бүленәчәк. Ә менә исәпләү җайланмасы куйдырмаганнарга җиңел булмас кебек: коммуналь хезмәтләр өчен түләгәндә, аларга норматив суммадан 1,5 тапкырга күбрәк түләттерергә җыеналар. Бәлки моннан соң счетчик куйдыручылар саны да артыр. Бишәр-алтышар кеше яшәп ятсалар да, фатирда беркем теркәлмәгән дип, су өчен аз түләүчеләргә дә көн бетәр сыман.

ЮЛЛАР

2 июньнән Казаннан Тбилисига туры авиарейслар ачылды. Очышлар атнага ике тапкыр башкарыла. Очыш вакыты 2 сәгать тә 40 минутны тәшкил итә. Шулай ук Казаннан Геленджикка да самолетлар оча башлаячак. Курорт шәһәреннән Казанга беренче рейс 13 июнь көнне очар дип көтелә. Рейслар сентябрь азагына кадәр башкарылачак. Очыш вакыты – 2 сәгать тә 25 минут. 13 июньнән Казаннан Пекинга да рейс ачылачак. Һава юлы дигәннән, 1 июньнән 4 июльгә кадәр, Конфедерация Кубогы матчлары белән бәйле рәвештә, спорт чаралары уза торган төп стадионнан 110 чакрым радиуста, 8100 метрдан да түбәнрәк очарга рөхсәт ителмәячәк.

1 июньнән «Юл куркынычсызлыгы турында»гы законга төзәтмәләр кертелә. Хәзер безнең илдә машина йөртүчеләрдән Россия машина йөртү таныклыгы таләп ителәчәк. Халыкара яки чит ил таныклыклары белән машина йөртү тыела. Исәпләүләр буенча, Россиядә 70 меңнән артык шофер Россия таныклыгы алырга өлгерми калган.

ЧАРАЛАР

Июньнең иң төп чараларының берсе – Конфедерация Кубогы. Казандагы беренче матч 18 июньдә узачак.

Рамазан аенда мөселманнар өчен 15 июньдә Казан академия теннисында республика ифтары оештырыла. Әлеге чарада ун мең кеше катнашыр дип көтелә. 25 июньдә Ураза гаетен билгеләп үтәчәкбез. Гает якшәмбегә туры килсә дә, яңа карар нигезендә, ул икенче көнгә күчерелми. Ә менә Россия көне уңаеннан, 10-12 июньдә өч көн ял туры килә.

ҺАВА ТОРЫШЫ

1 июньнән Татарстанда комлыклар сезоны ачылды. Тик елга буйлары әлегә буш. Өстән куртка төшмәгәндә, комлыклар турында хыялланырга гына кала. Июнь ае гадәттәгедән салкынрак һәм яңгырлы булыр, дип фаразлый синоптиклар.

Дөрес, бүгеннән һава температурасының 20 градуска кадәр җылынуы көтелә.

– Июнь тотрыксыз булыр кебек. Бу үз чиратында көтелмәгән табигать бәла-казаларына: көчле давылларга, шторм, яшенле яңгырларга китерергә мөмкин, – ди Казан федераль университетының метеорология кафедрасы җитәкчесе Юрий Переведенцев.

Чын җәйне июльдә генә көтәргә, ахры. Хәер, Ходайныкын белеп булмый. Синоптиклар үзләре дә, фаразлар 70 процент очракта гына дөреслеккә туры килә, диләр.

Шәһәр кәефе

ГОСМАН ГОМӘРОВ,
язучы:

– Иң изге айларның берсе – Рамазан ае бара. Уразага кергәч, һәр елны салкынча һава саклана. Аллаһының рәхмәте бу. Бездәге географик зонада көн яктылыгы озын. Шуның өстенә эссе дә булса, ураза тоту тагын да авырлашыр иде. Әлегә дингә килеп җитмәгән бер галим миңа: «Казан – догалы шәһәр», – дигән иде. Ходай Казанны догадан, иминлектән мәңге аермасын иде. Барча халыклар шушылай дус һәм тату гомер кичерик.

ЧУЛПАН ГЫЙЛЬМАНОВА,
студент:

– Агросәнәгать көллиятендә белем алам. Үзем Түбән Кама районының Шәңгәлче авылыннан. Казанда җәмәгать транспорты тукталышларына шәһәр картасын беркетсеннәр иде. Авыллардан, башка төбәкләрдән килгән кешеләргә кирәкле урамын табу җиңелрәк булыр иде. Ике кыз үстерәбез. Безнең әле чит илләргә дә, диңгезгә дә барганыбыз юк. Гаиләбез белән диңгезгә барырга хыялланабыз.

ӘЛФИНУР ЯКУПОВА,
почтальон:

– Балтач районының Түнтәр авылында 42 ел почтада эшләдем. Элек капчык-капчык хат, газета ташый идек. Интернет дөньяны үзгәртте, ләкин кешеләр газета укудан бизмәсеннәр иде. Хат та язып салу кирәк. Ата-ана ул хатларны кадерләп саклый, көн саен алып укый бит. Казанга еш килеп йөрим. Шәһәр урамнарында хуҗасыз этләрне күреп, котым оча. Шәһәрдә дә, авылда да хуҗасыз җәнлекләрне приютка җыйсыннар иде.

АИДА ИСХАКОВА,
студент:

– Казанның Киров районында туып-үстем. Энергетика өлкәсенә караган белгечлек үзләштерәм. Киров районында юллар, парклар бик үк әйбәт түгел әле. Петров паркы бар, ләкин ул гына бөтен районга җитми. Яңа Савин районындагы «Континент» кебек балалар паркы Киров районында да төзелсен иде. Буш вакытларымда чигү чигәм. Балабызга әле бер яшьтән артты гына, үсеп җиткәч, балабызның бөтен хыяллары да тормышка ашсын иде дип телим.

НАИЛ ИСМӘГЫЙЛОВ,
пенсионер:

– Тумышым белән мин Оренбург өлкәсенең Яңа Муса авылыннан. Казанда 2009 елдан яшим. Мәрхүм туганым язучы-педагог Рафаэль Мостафин турында биографик әсәр язып тәмамладым. Шуны китап итеп чыгарырга хыялланам. Студентлар өчен файдалы китап булыр иде ул. Казанда урамнарда транспорт чараларын идарә итүчеләрнең кайберләре җәяүлеләргә бигрәк игътибарсызлык күрсәтә. Штрафларны арттырасы иде.

Казанда очрашырбыз!

1 июньдә Казанда «Кунакчыл Казан» проектына старт бирелде. Республикабызга килүче туристлар саны елдан-ел арта. Алар өчен кызыклы экскурсияләр, маршрутлар уйлап табыла тора.

Туристларга хезмәт күрсәтүнең сыйфаты турында да уйланалар. Шуны күздә тотып барлыкка килгән «Кунакчыл Казан» проектының да максаты – килгән кунакларга башкалабыз һәм республикабыздагы туристлык маршрутлары һәм объектлары турында мәгълүмат бирү, Казанның туристлык җәлеп итүчәнлеген арттыру. Һәр мәгълүмати нокта футбол тубы формасында эшләнгән. Алар шәһәрнең кеше күп йөри торган биш урынында: Камал театры каршындагы мәйданда, Иске Татар бистәсендә, «Шаляпин» отеле, «Ногай» отеле, Казан Кремле янында урнашкан. «Татарстан туристлык волонтерлары ассамблеясе» җитәкчесе Юлия Бәширова чатырларда икешәр сменада өчәр волонтер эшләячәген хәбәр итте.

– Алар туристларга рус һәм инглиз телләрендә бөтен кирәкле мәгълүматны бирәчәк. Волонтерлар сайлап алын-

ды, алар махсус уку курсларын тәмамлады. Туристларга бирелдә бушка шәһәр картасы һәм «Татарстан: мең дә бер рәхәтлек» рәсми гиды биреләчәк. Гид рус, инглиз, немец, испан һәм кытай телләрендә басылган, – дип сөйләде ул журналистларга.

Брошюрада туристлык объектлары һәм маршрутлары турында киң мәгълүмат бирелгән. Кайсы экскурсиянең кайчан булачагы, ничә сәгатькә сузылачагы һәм ничә сум торуы да күрсәтелгән. Һәр ял төре категорияләргә бүленгән. Туристларга уңайлы булсын өчен валюта алыштыру, велосипедны прокатка алу, машина кую урыннары адреслары бирелгән. Җәй буена Казанда нинди вакыйгалар булачагы, театр-музейлар, туклану урыннары турында да мәгълүмат бар.

Чатырда волонтер булып эшләүче Алексей Ясонов сүзләренчә, алты көн эчендә барлык мәгълүмат нокталарына барысы бер мең турист мөрәҗәгать иткән. Алар арасында Италиядән килгән кунак аның хәтерендә бигрәк тә калган.

– Килеп керүгә үк «бәлеш» дия башлады. Бәлешне кайда ашап булуын сорарга теләгән икән. Аннары, сугансыз бәлеш русча ничек була, дип сорады. Мин инглиз хәрефләре белән русча язып бирдем дә Татар кулинариясе йортына озаттым. Турист кабат чатырга кайтып, рәхмәтен җиткерде, – ди ул.

Республиканың туризм буенча дәүләт комитеты җитәкчесе Сергей Иванов билгеләп үткәнчә, Конфедерацияләр Кубогы вакытында Казанда 150-200 мең турист көтелә. Бу Татарстан башкаласына килүче туристлар санының гадәти күрсәткеченнән 35-40 процентка артып китә.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

САН

*Казанның Самосырово чүплегендә **29** гектар мәйданга җәелгән, **45** метр биеклектәге чүп өемен чистарталар. Әлеге эш өчен бюджеттан **274** миллион сум акча бүленеп бирелгән. Киләчәктә чүплек урынында яшел таулар барлыкка киләчәк, ди.*

ТОП – 3

ДЕПУТАТЛАР, җәяүлегә юл бирмәгән өчен, автомобиль йөртүчеләргә җәзаны катгыйландырырга тәкъдим итә. Хәзер бу кагыйдәне бозган өчен 1500 сум штраф каралган булса, сумманы 2500 сумга күтәрергә дигән фикер яңгыраган. Административ хокук бозулар кодексындагы бу үзгәрешләрне Дәүләт Думасының законнар җыелмасы һәм дәүләт төзелеше буенча комитеты хупларга җыена, дип хәбәр итә «Известия».

РОССИЯНЕҢ Эчке эшләр министрлыгы чит ил паспортларын һәм машина йөртү таныклыгын рәсмиләштерү бәяләрен арттырырга җыена. Бу хакта Россия Дәүләт Думасына закон проекты тәкъдим ителгән. Ул кабул ителгән очракта, машина йөртү таныклыгын рәсмиләштерү 3000 сум торачак. Биометрик чит ил паспортын алу 5000 сумга төшәчәк. Хәзер бу хезмәт 3500 сумга төшә.

АЗ КЕРЕМЛЕЛӘРГӘ ризык алу өчен ярдәм күләме билгеләнгән. Беренчел исәпләүләр буенча, ул бер кешегә елына 10 мең тирәсе булыр, дип хәбәр итә «Интерфакс» агентлыгы. Россия сәнәгать һәм сәүдә министры Денис Мантуров әйтүенчә, азык-төлек ярдәме күрсәтү программасы киләсе елның икенче яртысында эшли башлаячак. Сораштырулар буенча, 26 процент россияле азык-төлек картасын алуга мохтаҗ.

КҮРШЕЛӘРДӘ

Башкортстан Республикасының 100 еллыгы алдыннан Уфада курайчылар флешмобы узачак. Салават Юлаев мәйданында ачык һавада 100 музыкант бер үк вакытта башкорт халык җыры «Урал»ны уйнаячак. Профессиональ башкаручылар белән беррәттән, үзешчәннәр дә катнашыр дип көтелә.

Чувашстанның җиденче сыйныф укучысы Софья Морозовага 12 июнь көнне Мәскәү Кремлендә паспорт тапшырачаклар. Кыз махсуслашкан кадет мәктәбендә белем ала. Ул – республика, шәһәр күләмендәге олимпиадалар җиңүчесе, мәктәп укучыларының Россия хәрәкәте активисты.

Мари Эл башлыгы вазифаларын вакытлыча башкаручы Александр Евстифеев республикада сөт җитештерүне арттырырга йөкләмә биргән. Соңгы 25 ел эчендә Мари Элда сөт җитештерү өч тапкырга кимегән. Җитәкче сөт җитештерү белән шөгыльләнгән предприятиеләрне барларга, савымны арттыру юлларын эзләргә кушкан.

Эшләп кеше үлми

Россиянең хезмәт һәм социаль яклау министры Максим Топилин эш вакыты дүрт сәгатькә кыскартылырга тиеш дигән фикер җиткергән, дип яза «Газета.ру». «XIX гасырда кеше тәүлегенә 12, 14, 16 сәгать эшләде. Бүген, XX гасырда көненә 8 эш сәгате стандарт булып санала. Кайбер илләрдә моннан да азрак эшлиләр», – дигән Топилин. Ә сез кеше ничә сәгать эшләргә тиеш дип санныйсыз?

Рамил ГАРИФУЛЛИН, психолог, психотерапевт:

– Кеше һәрчак эшләргә тиеш. Эш ихтыяр көчен арттыра, җанга дәва бирә. Безнең республикада чын-чынлап эшләүчеләр бик аз. Кубесе – хезмәт күрсәтүче. Әгәр минем клиентларым юк икән, димәк, эшем дә юк дигән сүз. Элек җитештерүчәнлек күләме зуррак иде, бүген күп тармаклар нефть аркасында яши. Кеше көненә ничә сәгать эшләргә тиеш дигәндә, бу һәркем өчен аерым билгеләнә. Хезмәт психологиясе дигән фән дә бар. Һәр кеше күпме эш башкарырга сәләтле икәнен үзе чамалый. Әгәр түземлеге җитми икән, ул эштән китә. Әлбәттә, ял да кирәк. Әмма бүгенге заманда, эшче һөнәрләр югала барганда, күп хезмәтне автоматлаштырылган роботлар башкарганда, кеше – күзәтүче ролендә. Эшләп арысаң гына чын хезмәт була. Кеше эшләргә теләми эшләгән шөгыль генә хезмәт дип атала. Яратып эшли икән, димәк, ул арымый, димәк, бу аның яраткан шөгыле. Бары хезмәт аркасында гына кеше яшьнең кадерен белергә өйрәнә. Эшләмичә ял итү – төрмәгә тиң.

Равил МИҢГАЛИЕВ, «Элекон» заводында 38 ел буе башкаручы директор булып эшләгән (хәзер лаеклы ялда):

– Заводта 69 ел эшләдем. Гади слесарь булып килгән идем, тора-бара зуррак дәрәҗәләргә ирештем. Яшь чакта шимбә көннәрендә дә, эштән соң калып та эшләргә туры килде. 78 яшемдә заводтан киттем. Эшләгән кеше картаймый. Эш булмагач, нишләргә белмисең, саташтыра башлый, кемдер эчүгә сабыша. Сигез сәгать эш сәгатен кыскартырга кирәк түгел дип саныйм. Эш планын да үтисе бар. Эшләмәсәң, акча да түләмиләр. Кесә юкаргач, тормыш авырлаша. Эшләп кеше үлми бит.

Шәһәр уртасында дөя яши...



Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Узган елларда Казанның Чистай урамы буйлап «сәяхәт итәргә» чыккан дөяне күреп, күпләр хәйран калды.

Әлеге хәлләрнең шаһиты булучылар, хайванны фотога һәм видеога төшереп, социаль челтәрләргә дә урнаштырдылар. Соңыннан мәгълүм булганча, тыныч кына үлән ашап йөрүче хайванны сак хезмәткәрләре хуҗасына илтеп тапшырган. Хәбәр астында калдырылган комментарийлардан аңлашылганча, «чүл корабы»ның хуҗасыннан беренче тапкыр гына качып китүе түгел икән инде.

Социаль челтәрләрдә дөянең хуҗасы Солдат урамында яши дисәләр дә, без аны, дөресрәге, дөя яши торган сарайны, Кемерово урамыннан эзләп таптык. Аннан кала биредә тагын ике пони, ат, янут, йорт куяны, тавыклар һәм бозау кадәрле өч эт яшәгәнлеге дә ачыкланды. Дөресен генә әйткәндә, әгәр биредә яшәүче хайваннарны үз күзләребез белән күрмәсәк һәм аларның «хуш исләре» борынны ярып кермәсә, сарайны ташландык дип уйлар идек. Кызганыч, бернichә тапкыр барсак та, Казан уртасындагы әлеге сарайның хуҗасын күреп сөйләшергә насыйп булмады. Шулай да күршеләреннән бернигә кадәр мәгълүмат белешә алдык.

Лариса, хуҗа хатынның исеме әнә шулай икән, әлеге сарайны арендага алып тора. Ә хайваннарны ул бәйрәм, ял көннәрендә паркларга алып чыгып, балаларның күңелен ачар өчен тота икән.

– Ларисаның эше җайланган аның. Тизәкләрен дә әрәм итми. Чират торып алып китәләр. Бер капчыгы – 100 сум. Шуңа агач чүбе дә кушылган булса, 150 сумга сата. Аты кәләшләре белән очрашуга атка атланып барырга теләүче егетләргә дә арендага бирел тора, – диде үзенең исемен әйтергә теләмәгән абый.

Аның сүзләренә караганда, хайваннар монда өч ел яши икән инде.

– Дөясе икәү иде, берсе үлде, бичара. Хайваннардан килгән ис сасы булса да, иләштек инде. Лариса бик тырыш хатын. Әгәр ул авылда яшәсә, мең дигән итеп тормыш көтәр иде. Килү белән үк өстен салып ата да, җиң сызганып, эшкә керешә, хайваннарны ашата. Дөясе ябык булса да, аты бик матур. Ә дөягә нәрсә аңа, алты айга бер ашаса да берни булмый, – дип көлдә яңа танышыбыз, уенын-чынын бергә кушып.

Әлеге дөянең Ларисага ничек килеп эләгү тарихын да бераз белә алдык. Дөрес булса, кирәксез, мескен хәлдәге дөяне ул, кызганып, циркта алып кайткан.

Зөһрә САДЫЙКОВА.

БУРЫЧ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

«Якын кешеңә дә ышаныч юк»

Эшкә килүемә мине редакциядә бер бабай көтеп тора иде. Борчуы бар: якын танышының энесенә, үз эшен ачар өчен, 500 мең сум акча биреп торган, хәзер бурычын кайтарып ала алмый. Ярдәм сорап, редакциябезгә килгән.

Эльвира МОЗАФФАР

Бабай дигәнем озак еллар Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә сәнгать җитәкчесе булып эшләгән Мөхәммәт Фәрзетдинов булып чыкты. Күпләр аны үткен телле, шаян алып баручы Марсель буларак белә.

– Композитор, җырчы Сара апа Садыйкованың концертларын еш алып бара идем. Ул бирде миңа бу исемне, – ди Мөхәммәт абый үзе.

Җырчылар белән дә филармониядә эшләгәндә дуслашкан.

– 2011 елда бер танышым (хәзер популяр җырчы) акча сорап килде. Үзенә түгел, энесенә. Аны 1990 еллардан бирле беләм. Һәрвакыт аралашып яшәдек. Ул мине концертларына гел чакырып торды. Белгән, ышанычлы кеше булгач, каршы килмәдем. Башта миллион сум сорадылар. Аның кадәр акча юк инде минем. Шулай да җыеп барган пенсия акчаларым банкта саклана иде, 500 мең сум акча алып бирдем. Бурычка акча алып торган Фәрит Ганиев бу хакта расписка да язды, – дип сөйли Мөхәммәт абый.

Ул бу кәгазьне редакциягә дә алып килгән иде. Фәрит Ганиев, чынлап та, үзенең паспорт мәгълүматларын күрсәтеп, Мөхәммәт Фәрзетдиновтан бурычка 500 мең сум акча алып торуы хакында язган. Бу акчаларны бер ел эчендә 750 мең сум итеп кайтарачакмын, дип тә вәгъдә иткән. Әмма җиде ел вакыт узса да, акча юк, ди. Мөхәммәт абый, бурычны кайтаруны сорап, Ганиевларга берничә тапкыр мөрәҗәгать иткән.

– Алар, зинһар, көтеп тор инде, дип ялвардылар. Имеш, бизнеслары килеп чыкмаган. 76 яшемдә тавыш куптарып йөрисем килмәде. Бу хакта балаларыма да белгертмәдем, – ди Мөхәммәт абый.

Әмма сабыр касәләре тулып, гомер буе җыйган акчасын кайтарырга теләмәүләрен сизеп, Мөхәммәт абый Фәрит Ганиевны судка биргән.

– Ходай ярдәменнән ташламый, шөкер. Ашарыма җитә, яшәргә урыным бар. 72 яшемә кадәр эшләдем. Гаделсезлек, мәрхәмәтсезлек борчый. Әллә бу миңа Ходайдан бирелгән сынаумы дип тә уйлап куям. Якын кешеңә дә ышаныч юк икән хәзер,– ди укучыбыз.

Бурычка акча алып торган Фәрит Ганиевка да шалтыраттык.

– Әйе, 2011 елда акча алып торган идем. Тик ике айдан бурычны кире кайтардым. Әле 50 мең өстәп тә бирдем. Мөхәммәт бабай янына өчәү килдек. Хатыным һәм уртак танышыбыз Гөлсинә дә бар иде. Тиз кирәк булгач, өстәп бирелгән 50 меңне шул Гөлсинәдән алып торырга туры килде. Бабай бик ашыга иде. Шуңа да акчаны санарга, расписка кәгазен алырга, бурычны кайтару турында кәгазь язарга вакыт та булмады. «Соңрак шалтыратышырбыз», – диде. Алты ел бернинди хәбәр бирмәде. Хәзер менә бабай акчаларны икенче тапкыр кайтарырга уйлый, күрәсең, – ди Фәрит Ганиев.

Мөхәммәт абый әйтүенчә, суд утырышына Ганиевлар килмәгән, шуңа да Совет районы суды беренче утырышны башка датага күчергән. Икенчесендә Мөхәммәт Фәрзетдинов файдасына, бурычны суд чыгымнары белән бергә 761 мең сум итеп кайтарырга тиеш, дип карар чыгарган. Әмма Фәрит абый моның белән килешмичә, апелляциягә биргән. Аның фикеренчә, расписка кәгазе өч ел гына гамәлдә, аннары үз көчен югалта. Өстәвенә, бу документ чын түгел, дип тә шикләнә. Расписка кәгазен экспертизага җибәргән.

– Әлегә нәтиҗәләр билгесез, әмма анда 1ле санын 4кә төзәткәне ярылып ята, – ди Фәрит абый.

Үзебездә булган расписка кәгазенең күчермәсен махсус карадык. Төзәтелгән урынны гына таба алмадык.

– Бәлки бабай ул акчаларны югалткандыр, әмма без кайтардык. Моны исбатларга уртак танышыбыз Гөлсинә дә бар. Без Мөхәммәт абыйга гел ышана идек, хәзер аптырашта калдык, – ди Фәрит абый.

Мөхәммәт Фәрзетдинов исә:

– Гөлсинәнең кем икәнен белмим, акчаларны кайтарган булсалар, расписка кәгазен миндә калдырмаслар иде. Аннары аларга башта ук, акчаны банкта бирәм, кире кайтарганда да банк бинасында тапшырасыз, дидем. Андый зур сумманы өйдә сакламас идем, – ди.

Кем хаклы, кем гаепле икәнлеге судта төгәл ачыкланыр. Бу хакта газетабызның киләсе саннарында хәбәр итәрбез.

Сорау, тәкъдим, фикерләрегезне редакциягә 8 (843) 562-50-12, 562-50-03 номерлары аша юллый аласыз.

БУРЫЧНЫ ТҮЛӘМӘСӘЛӘР НИШЛӘРГӘ?

Адвокат Сергей Комаров исә мондый очракларда өметне өзмәскә, акчаны кайтармаучы кешегә бурычы турында гел искәртеп торырга, шул ук вакытта документлар белән дә эш алып барырга киңәш итә.

– Судтан хөкем карарына башкарма кәгазь (исполнительный лист) алырга кирәк. Ул документны суд приставлары хезмәтенә тапшырыгыз. Бурычлы кешенең милке, мөлкәте тикшерелә. Бернәрсәсе булмаган очракта да, аның исәбендә акчалар барлыкка килүе бар. Әйтик, пенсиягә чыкты, аңа мирас күчте ди. Хәтта үзе вафатыннан соң да бурычы мирасны кабул итеп алучыларга: балаларына, хатынына күчә. Озак еллар бурычны кайтармау сумма194ның артуына китерүен дә онытмаска кирәк. Беренчедән, закон нигезендә, суд карарыннан соң да акчалар заем бирүчегә кайтарылмаган икән, аларга процент өстәлә, икенчедән, еллар узган саен, сумма индексацияләнә, – ди Сергей Комаров.

Күптән түгел редакциягә әҗәтен кайтара алмаучы тагын бер укучыбыз – Балтач районыннан Малик абый Рәхмәтуллин шалтыратты. Ул – II группа инвалид, пенсионер. Якташы – 1986 елгы яшь егет Рамил Зариповка 2012 елда берничә тапкыр акча биреп торган. Гомуми әҗәт 326697 сумга җыелган. Балтач районы суды, бу акчаларны Малик абыйга кайтарырга, дигән карар чыгарса да, үзгәреш юк. Укучыбыз, олы яшьтә булгач, бу акчаларны алу хокукын закон нигезендә кызы Илдариягә күчергән.

Әҗәтне ничек кайтарырга?

– Рамил: «Өйләнәм», – дип, әтидән акча алып торган иде. Ышандык, ярдәм итәргә теләдек. Расписка кәгазе дә язды, дөрес, анда бурычны кайчан кайтарачагы турында әйтмәгән. Рамилне судка бирергә мәҗбүр булдык. Суд безнең файдага карар чыгарды, әмма Рамил акчаларны кайтармый. Әлегә акчам юк, ди. Суд приставлары да чарасын күрми. Рамил рәсми төстә беркайда да эшләми, аның исемендә милек тә юк. Бурыч кайтармаган өчен мәҗбүри эшләргә тарту кебек җәза да каралмаган. Соңгы арада үзе белән дә сөйләшә алмыйбыз, телефоны җавап бирми. Әти-әнисе янына да барып карадык. Алар бу эшләргә тыкшынмаска булдылар. Нишләргә дә белгән юк, – ди Илдария.

Рәхмәтуллиннар: «Бәлки егет, язманы укып, оялып булса да, акчаларны кайтарыр», – дип өмет итә.

Без дә Рамилне эзләп карадык, кызганыч, телефонын гына алмады. Номерларын үзгәрткән, күрәсең.

Татарстанда кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиллектә әйдәп баручы киңәшче **Ренат МИҢГАЛИЕВ**:

– Иң якын кешеңә бурычка акча биреп торганда да кире кайтару вакытын төгәл билгеләргә кирәк. Әмма тәҗрибә күрсәткәнчә, килешенгән вакытка бурычны кайтаручылар сирәк. Әгәр сез бурычка акча алып торасыз яки үзегез әҗәткә бирәсез икән, ышанычлы булсын өчен, ике арада заем килешүе төзергә киңәш ителә. Бер як – заем бирүче (бурычка акча бирүче кеше), икенчесе (акча алып торучы) заемщик дип атала. Россия Гражданнар кодексының 808нче маддәсе буенча, заем килешүе язмача төзелергә тиеш. Иң ышанычлысы һәм гадие – расписка кәгазе алу. Әмма расписка – килешүнамә түгел, һәм ул килешү өстенлекләренә дә ия була алмый. Бурыч кайтару-кайтармау мәсьәләсе хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла, шуңа да бу мәсьәләне бары суд аша гына хәл итеп була. Расписканың гамәлдән чыгу вакыты закон белән чикләнмәгән, әмма дәгъваның срогы өч ел гына тәшкил итә. Шуңа да, хокукларын яклау өчен, кеше судка мөмкин кадәр иртәрәк мөрәҗәгать итәргә тиеш.

Бездән нинди ташламаларны яшерәләр?

Безнең илдә тиеш булган ташламалар да, матди ярдәм төрләре дә шактый, әмма күпләребез алар турында белеп кенә бетерми. Җаваплы кешеләр әйтеп-аңлатып торуны кирәксенми, ә халык рәсми документларны тикшерергә иренә, хәттә билгеле бер төр ташламалар барлыгы турында башына да китерми.

Зөһрә САДЫЙКОВА

НИНДИ ЯРДӘМ ТИЕШЛЕГЕН КАЯН БЕЛЕРГӘ?

Салым ташламалары, салым чигерүе
Федераль салым хезмәтенең урындагы бүлеге (**www.nalog.ru**)

Бушлай дарулар, медицина ярдәме
(**www.ffoms.ru, minzdrav.tatar.ru**)

Авиа һәм тимер юл транспортына ташламалар
Росавиация (**www.favt.ru, www.rzd.ru**)

Бала, декрет акчалары, бушлай санаторий-курорт дәвалануы, инвалидлар, профессиональ авырулы эшчеләр, җитештерүдә зыян күргән кешеләр хокукы
Социаль иминият фонды бүлеге (**www.fss.ru**)

Күп балалы гаиләләргә, хезмәт ветераннарына тиешле ташламалар, шәһәр транспортында бушлай йөрү буенча мәсьәләләр
Социаль яклау бүлекләре, күп функцияле үзәкләр

Федераль ташламага ия булучыларга айлык түләүләр, пенсиягә өстәмәләр, ана капиталы
Пенсия фонды бүлеге (**www.pfrf.ru**)

БЕЛЕП ТОР!

– Илдәге ташламаларның барысы да диярлек халыктан килеп ирешкән гариза нигезендә күрсәтелә. Ягъни җитәкче исеменә гариза язып, үзең ярдәм сорамыйсың икән, сиңа беркем дә китереп бирмәячәк, – диделәр безгә республиканың Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында.

Шуңа күрә халык күзеннән һәм колагыннан бераз читтәрәк калган, әмма һичшиксез тиеш булган ташламалар турында тәфсилләбрәк аңлатып язарбыз.

БАЛАЛАРГА

Һәр җан башына уртача керем яшәү минимумыннан кимрәк булган балалы гаиләләрдәге 16 яшькә кадәр малай-кызлар өчен (әгәр яшүсмер гомумбелем бирү учреждениесендә укыса, 18 яшькә кадәр) айлык пособие түләнә. Быелның 1 гыйнварыннан Татарстанда аның күләме – 295 сум, ялгыз ананың баласына – 782 сум, хәрби, чакырылыш буенча хәрби хезмәттәге кешенең улына-кызына, алимент түләүдән качып йөрүченең баласына 442 сумны тәшкил итә.

Моннан кала, шулай ук җан башына уртача керем яшәү минимумыннан кимрәк булган очракта, өч яшькә кадәрге һәм хроник авырулары булган, яшәү урыны буенча сырхауханәдә амбулатор учетта торган сабыйлар табиб рецепты буенча сөт ризыклары һәм катнашмалар белән тәэмин ителергә тиеш. Моның өчен социаль яклау бүлекләренә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Закон буенча, яңа туган һәр сабыйга бушлай аптечка да каралган. Аңа марганцовка, тамызгыч (пипетка), марля, термометр һәм башка кирәкле әйберләр керә. Бу хактагы мәгълүматны педиатр җиткерергә тиеш булса да, ни өчендер, әйтми калуны кулайрак күрә. Шунысын да истән чыгарырга ярамый: аптечканы сабыйга бер ай булганчы ук алырга кирәк. Моның өчен участок табибына баланың туу турындагы таныклыгын, медицина иминиятен һәм әти-әнинең паспортларының күчермәләрен тапшырырга кирәк.

Яшь әниләр белеп торырга тиешле тагын бер ташлама бар. Ул – өч яшькә кадәрге сабыйларны (күп балалы гаиләләрдә – 6, инвалидларга 18 яшькә кадәр) бушлай дару белән тәэмин итү. Менә монысыннан чыннан да бик сирәкләр генә хәбәрдар. Татарстанның Сәламәтлек саклау министрлыгы белгечләре аңлатканча, әлеге дарулар исемлеген Татарстанның Министрлар Кабинеты бюджет мөмкинлегеннән чыгып билгели. Закон буенча, әлеге ташлама турында педиатр әйтергә, исемлеккә кертелгән дарулар белән таныштырырга һәм аларны махсус бланкка язып бирергә тиеш. Дарулар исемлеген Сәламәтлек саклау министрлыгы сайтыннан да карарга мөмкин. Анда, мәсәлән, инфекцияләрне профилактикалау һәм дәвалау өчен – амоксициллин, азитромицин, синтетик бактерияләргә каршы – сульфацетамид, эчәклекләрнең эчке тирәлеген торгызу өчен – бифидумбакте, энтерол, сулыш алу органнарына тәэсир итә торган недокромил, витаминнардан никотиновая кислота тәкъдим ителгән.

ӘНИЛӘРГӘ

Балалары булган гаиләләр салымны азрак түли. Аны әни дә, әти дә (икесе дә!), уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр алырга хокуклы. Әлеге ташлама яшүсмергә 18 яшь тулганчыга кадәр бирелә. Әгәр ул уку йортының көндезге бүлегендә укыса, 24 яшькә кадәр алырга мөмкин. Салым чигерүе беренче һәм икенче балага – 1400 сум, өч һәм аннан соңгыларга – 3 мең, инвалидка 12 мең сум тәшкил итә. Әгәр ир яки хатын ялгыз, яисә тол калса, баласын ялгыз тәрбияләсә (баланың туу турындагы таныклыгында атасы турында мәгълүмат күрсәтелмәгән булса), яки парның берсе салым чигерүеннән язма рәвештә баш тартса, бу сумманы икегә тапкырларга кирәк.

– Бу – кайтарырга мөмкин булган акча түгел. Әлеге суммадан керемгә салына торган 13 процент салым тотылмый дигән сүз. Мәсәлән, өч балалы әнигә айлык ташлама күләме түбәндәгечә исәпләнә. Сезнең айлык хезмәт хакыгыз 30 мең сум, ди. Шуннан өч балага (1400+1400+3000) 5800 сумны чигерәбез. Һәм 13 процент салым шуның калганыннан алына, – дип аңлата белгечләр.

Дөрес, чикләү дә бар. Салым чигерүе хезмәткәрнең еллык кереме 350 мең сумлык чиккә җиткәнче генә бирелә.

Болардан кала, закон буенча, түләүле медицина хезмәтеннән файдаланган яки дарулар сатып алган һәркем салым чигерүенә хокуклы.

ПЕНСИОНЕРЛАРГА

Бөтен пенсионерлар (шул исәптән эшләүчеләр дә) бер фатирга, бер йортка һәм бер гаражга милек салымыннан азат ителә. Моннан файдалану өчен салым хезмәтенә гариза язып мөрәҗәгать итәргә кирәк. Әгәр пенсионерның ике фатиры булса, түләргә теләмәгәнен күрсәтү яхшырак.

Моннан кала, өлкән яшьтәгеләргә Пенсия фонды аша бирелә торган ташламалар шактый. Мәсәлән, пенсионерларның 50 категориясе – айлык акчалата түләү (ЕДВ), 12се – өстәмә матди ярдәм (ДМО), 7се өстәмә айлык матди ярдәм алырга хокуклы. Мәсәлән, II-IV дәрәҗәдәге «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен» орденына яки СССР (Россия) дәүләт премияләренә лаек булганнарның пенсияләренә өстәп 16 мең сум акча бирү каралган. Әмма дәүләт бүләкләре алу турында Пенсия фондына шунда ук хәбәр итәргә кирәк. Соңрак гариза язган очракта, компенсация түләнмәячәк.

ПАССАЖИРЛАРГА

Җәйге ял сезонына кердек. Ә Россия курортларында ял итәргә теләүчеләрнең күпчелеге поездда баруны кулайрак күрә, шуңа күрә кайбер хокукларыгызны да белеп тору комачауламас. Ерак юлга хәрәкәт итә торган поездларда биш яше тулмаган бер балага (аерым урынга утырмаса), ә биш-ун яшьлек балаларга билет сатып алганда 65 процент ташлама каралган. Озатып баручыдан шулай ук өстәл уеннарын – шашка, шахмат, домино, ә кайбер поездларда китап та сорап алырга мөмкин.

ЭШЧЕЛӘРГӘ

Күп кенә кешеләр үзләренең эш хокуклары турында да белеп бетерми.

– Әгәр сезнең эш көнегез нормага салынмаган булса, отпускка кимендә өч көн өстәлергә тиеш. Шулай ук 14 яшьтән кечерәк балалары булган кешеләр тулы булмаган эш көненә дә күчә ала. Сабыена өч яшь тулганчы, әни командировкага барудан, өйгә өстәмә эш алудан, төнлә, ял һәм бәйрәм көннәрендә эшләүдән баш тартырга хокуклы, – ди юрист Сергей Саурин.

СОРАУ-ҖАВАП

МРТны бушлай уза аламмы?

– Күптән түгел мин үзебезнең сырхауханәдә табиб-невролог янында булган идем. Баш, муен авыртуыннан, баш әйләнүеннән зарлангач, ул миңа умыртка баганасының муен өлешенә МРТ төшерергә кушты. Моннан ике ел элек акча түләп, баш миенә МРТ ясаткан идем инде. Тик аны бушлай да эшләтеп була икән дип ишеттем. Шул турыда аңлатыбрак язсагыз иде.

Алсу Хәкимова, Казан.

Сорауга «Ак Барс-Мед» иминият компаниясе менеджеры **Аида** җавап бирә.

– МРТның кайбер төрләре, шул исәптән баш мие һәм умыртка баганасының муен өлешен тикшерү мәҗбүри медицина иминиятләштерүе системасына кертелгән. Аны яшәү урыны буенча сырхауханәдәге табибның рәсми күрсәтмәсе нигезендә генә ясыйлар. Иң элек табиб направление биреп, амбулатор картага яза, аннан соң сезне чиратка куялар. Шуннан соң дәүләт гарантиясе программасы буенча, 30 көн эчендә республиканың Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан квота күчерелә.

Гомумән алганда, мәҗбүри медицина иминиятләштерүе полисына кертелгән медицина ярдәмнәре бик күп. Монда территориаль сырхауханәләр күрсәтә торган бөтен төр медицина хезмәтләре кертелгән. Шулай ук махсуслашкан ярдәмгә карый торган медицина хезмәт күрсәтүенә дә өметләнергә була. Тулырак мәгълүматны исә www.ffoms.ru сайтына кереп, «Гражданнарның бушлай медицина ярдәме алуга дәүләт гарантияләре программасы – 2017» бүлегеннән алырга мөмкин. Шунысын истә тотарга кирәк: түләүле хезмәт күрсәтү килешүенә кул куйганчы, әлеге иминият компаниясенең «кайнар элемтә» телефонына чыгып, теге яки бу хезмәтнең бушлай күрсәтелүен-күрсәтелмәвен белешергә кирәк, чөнки аннан соң компенсация түләнмәячәк.

Алисә САБИРОВА әзерләде

ИЛГӘ ЭШЧЕЛӘР
Авыл хуҗалыгы белгечләрен

АБИТУРИЕНТЛАРГА ЯРДӘМГӘ УКУ ЙОРТЛАРЫН БАРЛАУНЫ ДӘВАМ ИТӘБЕЗ. БҮГЕН БЕЗ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ТАРМАГЫНДА БЕЛГЕЧЛӘР ӘЗЕРЛИ ТОРГАН УКУ ЙОРТЛАРЫНА ТУКТАЛДЫК.

КАЗАН ДӘҮЛӘТ АГРАР УНИВЕРСИТЕТЫ

Заманында республиканың Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белем алган уку йорты бу. Биредә бүген 22 белгечлек буенча биш меңнән артык студент белем ала, 12 юнәлештә бакалавр, 7 юнәлештә магистрлар әзерләнә. Сүз уңаеннан, май аенда аграр университет 95 яшьлек зур юбилеен үткәрде.

Студентлар агрария, урман хуҗалыгы һәм экология, механикалаштыру һәм техник сервис, икътисад кебек дүрт юнәлештә белем ала. Югары белемле агроном, бакчачы, урманчы, ландшафт дизайнеры, эколог, агроинженер, икътисадчы әзерлиләр. Шунысын әйтергә кирәк, икътисади белем монда бары тик түләүле генә. Читтән килеп белем алучы студентларга тулай торак та бар.

Укырга керү өчен математика белән рус теленнән кала, факультетына карап, биология, география, физика яки җәмгыять белеменнән дә имтихан тапшырырга кирәк. Кайбер сәбәпләр аркасында түләп укырга теләүчеләр өчен белем алу бәясе 90-100 мең сум тирәсе дип язылган уку йорты сайтында. БДИ баллары яхшы булган абитуриентларга 10-20 мең сум ташлама да каралган. Белем алу вакыты бакалавр юнәлешендә – дүрт ел.

– Соңгы вакытта яшьләр аграр белемне диплом алу өчен генә түгел, ә үз белгечлеге буенча авыл җирлегендә эшләү өчен ала. Хәзер авылда эшләүче яшьләргә республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан бик күп кызыксындыру чаралары оештырыла. Әйтик, инде студент вакытта укучы, берәр оешма белән килешү төзеп, ун меңлек стипендия алырга мөмкин. Ягъни студентка, дәүләттән тыш, киләчәктә эшләячәк оешма да акчалата ярдәм итә. Укып бетергәч тә, министрлык яшь белгечләрне ташламый. Авылда төпләнгән очракта, аларга 300 мең сум «подъемный» бирелә. Бер ел дәвамында хезмәт хакына минималь керем өстәлеп бара, торакка субсидия бирелә, – диде уку йортының кабул итү комиссиясе җаваплы сәркатибе Гүзәл Фәссахова.

Инде университет калыбына гына сыймаган студентлар үзләрен Германиядә сынап карый ала. Уку йорты Германия аграр университетлары белән тыгыз элемтәдә тора. Шулай ук студентларга эшмәкәрләр, төрле оешма җитәкчеләре, сәясәтчеләр дә дәрес бирә.

Аграр университет – спорт, иҗат өлкәсендә күп кенә Казан вузларына үрнәк. Әле күптән түгел генә уку йортының «Әкәмәт» ШТК командасы Югары татар лигасында җиңү яулады. Университетның «Тургай» студентлар халык театр төркеме республика районнарыннан гастрольләрдән кайтып та керми.

Адресы: К.Маркс урамы, 65 нче йорт
Телефоны: (843) 567-46-30

УРТАЧА БАЛЛ
Агрономия факультеты – 150-176 балл
Механизация һәм техник-сервис институты – 160-176 балл
Урман хуҗалыгы һәм экология факультеты – 160-192 балл
Икътисад институты – 165-185 балл

БАУМАН ИСЕМЕНДӘГЕ КАЗАН ДӘҮЛӘТ ВЕТЕРИНАРИЯ МЕДИЦИНАСЫ АКАДЕМИЯСЕ

Академия – Россиядә ветеринария юнәлешендә белем бирә торган иң борынгы уку йортларының берсе.

«Ветеринария медицинасы» факультетында мал табибы һәм ветеринария-санитар экспертиза белгечлекләре буенча белем бирәләр. Мал табибы һөнәрен үзләштергәннәр соңгы курсларда кош, балык, бал кортлары авырулары, кинология нигезе һәм этләр анатомиясе, йорт хайваннары һәм экзотик җанварларны дәвалау һ.б. өстәмә юнәлешләрне инде тирәнтен үзләштерә башлый. Читтән торып һәм кичке бүлектә дә укырга мөмкин.

«Биотехнологияләр һәм стандартлаштыру» факультетында зоотехния, стандартлаштыру һәм метрология, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү, менеджмент кебек юнәлешләрне үзләштереп була.

– Гадәттә, бер урынга өч-дүрт кеше туры килә. Өч фәннән БДИ буенча уртача балл – 150. Иң зур конкурс мал табибы белгечлегенә, биредә 173тән дә кимрәк балл белән кереп булмый. Студентларыбыз III курстан практик дәресләргә күчә. Аны авыл хуҗалыгында да, Казан ветеринария клиникаларында да узарга мөмкин. Академияне тәмамлаган студентларның барысын да эшкә урнаштырып барабыз, – диде уку йортының кабул итү комиссиясе җаваплы сәркатибе Рубин Каюмов.

Ветеринария академиясе дә студентларны чит илгә укырга җибәрә. «Аполло» программасы аша ел саен бернichә студент Германия, Дания, Франция, Казахстан, Төркия университетларында белем дәрәҗәсен күтәрә. Төп таләп – барасы ил телен белү.

Адресы: Себер тракты урамы, 35нче йорт
Телефоны: 8 (843) 273-96-46

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ӘТНӘ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ТЕХНИКУМЫ

Әтнәгә бер килүендә Рөстәм Миңнеханов, уку йортындагы шартларга шаккатып, техникумны студентлар кампусы, ягъни студентлар шәһәрчеге дип атаган иде. Дөрестән дә, техникумда булмаган нәрсә юк.

2016 ел Әтнә авыл хуҗалыгы техникумы өчен иң истә калырлык ел булган. Беренчедән, уку йорты 50 яшьлек юбилеен үткәрә. Икенчедән, узган ел биредә эшче һөнәрләр әзерләү буенча республика үзәге ачылган. Ресурс үзәк укыту системасын гына түгел, техникумның бинасын да үзгәртә. Андагы ремонтка, 30 миллионлык лаборатория җиһазларына хәтта Казанның югары уку йортлары көнләшә.

Ярты гасыр дәвер эчендә техникум авыл хуҗалыгы өлкәсендә эшләүче 9 меңнән артык белгеч әзерләргә өлгергән. Биредә аш-су остасы, бухгалтер-икътисадчы, ветеринария, техник-механик кебек дүрт юнәлеш буенча белем бирәләр. Киләчәктә эретеп ябыштыручы, электрик һөнәрләрен дә үзләштереп булачак монда. Абитуриентларны 9нчы сыйныфтан укырга алалар. 11нче сыйныфлар исә механик һәм бухгалтер белгечлегенә читтән торып укый. Студентлар бер генә һөнәр белән чикләнми. Төп укулары тәмамлагач, дүрт-биш ай эчендә яңа һөнәр дә үзләштерә алалар. Моңа өстәп, студентлар B, C категориясендә машина йөртү таныклыгы да ала. Трактор йөртергә дә өйрәнеп була. Уку йорты янында гына автодром бар.

Бу уку елыннан техникумда имтихан бирү системасы да үзгәрде. Элек чыгарылышлар бары диплом гына якласа, хәзер демонстрацион имтихан да тапшыра. Бу сынау парта артында үтми. Яшьләр үз белемнәрен практикада сыный. Әйтик, механиклар имтиханда тракторларга техник ярдәм күрсәтү, фрес, культиватор, чәчкеч белән эшләү осталыгын күрсәтергә тиеш. Диплом алу өчен студентка 100 балл җыярга кирәк.

Уку белән генә дөнья бармый. Спорт белән шөгыльләнү өчен уку йорты бинасында тренажер залы, спорт залы бар, ишегалдында исә мини футбол, баскетбол, волейбол мәйданчыклары җиһазландырылган. Сүз уңаеннан, узган уку елында техникум командасы мини футбол буенча республика чемпионы булды. Ә Алабуга шәһәрендә студентлар арасында узган спартакиадада өченче урын яуладылар. Җыр, биюгә студентларны Казан белгечләре өйрәтә. Җырчы Гөлназ Солтанова исә вокал буенча дәресләр бирә. Быелгы сентябрьдән техникумда театр түгәрәге эшли башлый. Ул рәсми булмаган Әтнә дәүләт драма театрының яшьләр филиалы булыр дип көтелә. Студентлар белән театр артистлары үзләре шөгыльләнәчәк. Биредә WorldSkills хәрәкәте дә көчле. Узган ел студентлар аш-су остасы, ветеринар белгечлекләре буенча үзләрен чемпионатта сынап караган.

Техникум тәмамлаган яшь белгеч үз юнәлеше буенча Казан дәүләт аграр университеты белән Бауман исемендәге Казан ветеринария университетына БДИсыз укырга керә ала. Бу очракта уку вакыты кыскартыла.

Адресы: Зур Әтнә, Б.Җиһаншин урамы, 87нче йорт
Телефон: 8(84369)2-13-10, 2-13-13

КИРӘК – 2

әзерли торган уку йортлары

САБА АГРАР КӨЛЛИЯТЕ

Саба көллиятенә керсәң, андагы тәртипкә шаккатасың. Студентлар, мәктәп укучылары кебек, бердәм формадан йөри. Иртәләрен йога белән шөгыльләнәләр, ә «линейка» вакытында концертлар куялар. Кыскасы, монда үзеңне төрле яктан күрсәтергә бөтен мөмкинлек тә бар.

Башка уку йортларындагы кебек, биредә дә «Авыл хуҗалыгы механизациясе», «Тракторист-машинист», «Электр энергиясе белән тәэмин ителеш», «Бина, корылмаларны төзү, куллану», «Икътисад һәм бухгалтер хисабы» юнәлешендә белем бирәләр. Уку, белгечлегенә карап, ике-өч елга кадәр сузыла.

Сабадан тыш Балтач, Кукмара, Арча, Теләче районнары, Киров өлкәсе, Казан шәһәреннән килеп укучылар да бар.

Икътисади белем алучы кызлар, гадәттә, Казан дәүләт авыл хуҗалыгы университетына һәм Казан милли-тикшеренү технология университетына (КХТИ) III курска укырга керәләр. Егетләрнең 60 проценты башта армия хезмәтенә барып кайта, соңыннан авыл хуҗалыгы өлкәсендә эшли башлый. Укучыларның 70-80 проценты үз һөнәре буенча эшкә урнаша.

Укучыларны төп имтихан һәм аттестатка карап сайлап алалар. Шулай ук уку йортының үзендә математика һәм рус теле буенча имтиханнар була. Абитуриент белән сөйләшүләр алып барыла, ләкин бу сынаулардан артык куркырга кирәкми.

– Безнең төп максат – тәрбия. Балага никадәр белем бирсәң дә, тәрбиясе булмаса, ул белемен тиешенчә куллана алмаячак. Сер түгел, бездә авыр хәлле гаиләләрдән килгән, әтисе йә әнисе эчкече булган балалар да укый. Алар безгә укырга килеп башка – матур тормыш та бар икәнен күрә, үзләре шуңа омтыла башлый. I курска килгән кайбер малайлар урын-җирләрен дә җыя белмиләр. Тулай торакта алар чисталыкка, пөхтәлеккә өйрәнә. Соңыннан әти-әниләре килеп рәхмәтләр әйтә. Мәктәптәге укытучылары «бу баланы дәрестә дәфтәр тотып шигырь укытып булмый иде» дип зарлана. Ә бездә алар гөрләтеп җырлый, бии, сәхнәләргә чыга. Мәктәптә көчкә «өчле»гә тартучылар монда ныклы «дүртле» билгесенә укый башлый, – ди Саба аграр көллиятенең директор урынбасары Рәнис Якупов.

Адресы: Байлар Сабасы,
Кол Гали урамы, 45нче йорт
Телефоны: 8 (84362) 2-21-78

САРМАН АГРАР КӨЛЛИЯТЕ

Сарман аграр көллияте укучылары комбайн, трактор йөртергә махсус тренажерларда гына өйрәнә. Алардан соң теләсә кайсы техникага утыру куркыныч түгел. Белемнәрне гамәлдә куллану өчен көллиятнең 19 тракторы, 6 комбайны, 78 авыл хуҗалыгы машинасы, 800 гектар җире дә бар әле.

Сарманның үзеннән тыш биредә Азнакай, Әлмәт, Әгерҗе, Зәй, Тукай күрше районнарыннан да белем алырга киләләр. Биредә авыл хуҗалыгы механизациясе, эретеп ябыштыручы, җәмәгать туклануы продукциясе технологиясе, авыл хуҗалыгы тармагында эшләүче тракторист-машинист юнәлешендә белем бирәләр. Шулай ук өстәмә рәвештә бульдозер, экскаватор йөртүче, аш-су остасы, ЭВМ операторы һөнәрләрен үзләштерәп була.

– Безнең көллият техник-механиклары белән дан тота. Бу белгечлекне алу өчен ераклардан кызыгып укырга киләләр. Без кластерлы белем бирү системасына кергән. Студентларыбыз көллиятне тәмамлагач, аграр университетына, алган белгечлекләре буенча, III курска укырга керә алалар. Мондый мөмкинлек һәр уку йортында да юк. Республика буенча бары 6 көллият һәм 2 техникум гына югары уку йортына бюджет урыннарына укырга кертә ала. Без – шуларның берсе. Моның өчен чыгарылышларга математика, рус теле һәм физика фәннәреннән генә имтихан тапшырасы, – диде көллиятнең директор урынбасары Илфат Нигъмәтуллин.

Соңгы елларда сарманлылар WorldSkills эшче һөнәрләр чемпионатына да актив кушылган. Биредә, авыл хуҗалыгы өлкәсендә эшләүче белгечләрнең белемен чарлау өчен, ресурс үзәге дә ачылды. Әлеге максаттан 63 миллионлык капиталь ремонт ясалган. Тагын 50 миллионга заманча техника сатып алынган. Ябык полигоннарында исә ел саен республика чемпионатлары оештырыла.

– WorldSkills буенча безнең беренче өчлектән төшкән юк. Күптән түгел бер укучыбыз Белгородта барган ярышларда 39 төбәк арасында IX урын алып кайтты. Ел саен Ачык ишекләр көнендә 9нчы сыйныфларга экскурсия оештырабыз. Кайвакыт балалар, сездә бүген ук калсак ярыймы, дип кызыгып китәләр, – ди Илфат Нигъмәтуллин.

Бүген көллиятнең көндезге бүлегендә 770 студент белем ала.

Адресы: Сарман, Ленин урамы, 37нче йорт
Телефоны: 8(855)-592-53-53

ЛУБЯН УРМАН ХУҖАЛЫГЫ КӨЛЛИЯТЕ

Көллият Кукмара районының Лубян авылында урнашкан. Әйләнә-тирәсе, Тукай әкиятләрендәге кебек, кара урман белән уралган. Бу – республикада урман хуҗалыгы нигезләренә өйрәтүче бердәнбер көллият. 95 ел эчендә ул 9 меңгә якын урман хуҗалыгы белгече әзерләгән.

Башка уку йортларында күбрәк теориягә игътибар итсәләр, монда алар практика белән үрелеп бара. Бераз гына белем туплыйсың да, аны гамәлдә кулланып карау өчен, урманга чыгасың. Моның өчен барлык шартлар да тудырылган: теләсәң – урманы, теләсәң, 6 гектардан артык питомнигы бар уку йортының. Соңгысында студентлар төрле агачлар үстереп карый. Төп фәннәр – ботаника, урманны саклау (лесозащита), дендрарий, туфрак белеме (почвоведение).

Бирегә укучыларны IX, XI сыйныф базасында алалар. «Урман һәм урман парк хуҗалыгы» бүлегенә быел 50 бюджет урыны бүленгән. «Бакча-парк һәм ландшафт төзелеше» бүлегенә исә 25 кеше бюджет урыннарына укырга керә ала. Шуның кадәр үк урын «Икътисад һәм бухгалтер учеты» белгечлегенә бүленгән.

11нче сыйныфтан соң читтән торып белем алалар. Урман кисүче, чыбыктан сәнгать әшләнмәләре ясау, урман хезмәткәре, агач эшкәртә торган станоклар белән эшләүче, авыл хуҗалыгы өлкәсендә эшләүче тракторчы-машинист, урманчы (егерь) белгечлекләрен үзләштереп була. Тулай торак каралган.

Адресы: Кукмара районы, Лубян авылы, Техникум урамы, 10нчы йорт
Телефоны: 8(84364) 2-31-66

РОССИЯДӘ БҮГЕН ТАЛӘП ИТЕЛГӘН УН ҺӨНӘР

- *Автомеханик*
- *График дизайнер*
- *Химик анализ лаборанты*
- *Агач остасы*
- *Повар-кондитер*
- *Эретеп ябыштыручы*
- *Авыл хуҗалыгы өлкәсендә эшләүче техник-механик*
- *Токарь-универсал*
- *Фрезеровщик-универсал*
- *Электр монтажлаучы*

Ял итәргә өйрәнергә кирәк

Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы белгечләре: «Тулы көченә ял итәр өчен, кешегә өч атна вакыт кирәк, отпуск аннан да ким булырга тиеш түгел», – дип белдерә. Аларның сүзләренчә, кыска ялдан соң хезмәткәрләр, ялга кадәрге чорга караганда, 30-50 процентка начаррак эшли. Өч атна ялдан соң исә алар батырып эшли икән. Шуңа да табиблар, беренче атна – адаптация, икенче атна – ял, өченче атна элеккеге яшәү режимына кайту өчен кирәк, дигән нәтиҗәгә килгән. Ә менә психологлар табиблар белән килешми, ялны берничә өлешкә бүләргә киңәш итәләр. Алар, кеше елына, ким дигәндә, өч тапкыр ял итәргә тиеш, дигән фикердә тора. Иң нәтиҗәле ял нинди була һәм ул ничә көнгә сузылырга тиеш? Психолог Наилә Бәширова белән без шул хакта сөйләштек.

vk.com

– Кеше, кимендә, ике, ә иң күбе өч атна ял итәргә тиеш. Ялның сыйфаты көннәргә бәйле түгел, ул аны ничек үткәрүеңнән тора. Дөресен әйткәндә, без ял итә белмибез. Кайберәүләр өчен ял – стресс. Эшләп кенә яшәргә күнеккән кеше ялда да эше турында уйлый, шалтыратуларга җавап бирә. Ялга кадәр башлаган эшен төгәлләп бетермәгән булса, бигрәк тә. Шуның өчен үзеңне гаепле итеп сизәсең, борчыласың. Эштәге хәл итеп бетерелмәгән мәсьәләләрне соңгы көнгә кадәр тартып-сузып килмәгез, ялга кадәр эшләп бетереп китегез. Бүген соңгы эш көнен тәмамлап кайтып, иртәгә кинәт кенә бөтен нәрсәне онытып ял итәргә керешү дә авыр. Шуңа да мин отпускка кадәр һәр көнне берәр сәгать телефон, интернетсыз, телевизорсыз ял итәргә киңәш итәм. Якындагы паркка чыгып китәсең дә табигатькә хозурланып йөрисең. Иптәшкә кемне дә булса алырга кирәкми, ялгыз чыгарга тырышыгыз. Болай иткәндә, ике атна ял да җитә, – ди психолог.

Наилә Бәширова фикеренчә, ял итү мәсьәләсендә безгә һиндлардан үрнәк алырга кирәк.

– Алар минем ял итәргә хокукым бар, мин аңа лаек дигән девиз белән яши. Аларда шундый гыйбарә дә бар: яхшы итеп эшләү өчен яхшы итеп ял итәргә кирәк, – ди ул.

Наилә Бәшировадан тагын бер киңәш – берәр кая ялга барырга теләүчеләргә кредит алмау хәерле. Ял итеп кайтасың да, бер-ике атнадан кредит түләү вакыты җитә. Монда инде ялың онытыла да куя. Кредит алганчы, яхшылап уйлагыз: бәлки, арзанрак юллама белән барып була торган ил бардыр, бәлки, биш йолдызлы ук кунакханәдә яшәргә кирәкмидер? Океанны – диңгезгә, диңгезне күлгә алыштырып була бит. Барысын да уйлап-исәпләп чыгаргач, ял алай кыйммәткә дә төшмәскә мөмкин.

Кайберәүләр берничәшәр ел рәттән ял алмый эшли. Психолог әйтүенчә, бу, һичшиксез, кешенең сәламәтлегендә чагылачак. Организмның ресурсын илле елда да, җитмеш ел эчендә дә сарыф итәргә мөмкин. Ялсыз кеше таушала, энергиясе бетә.

Ялдан соң эшкә дә чыгасы бар бит әле. Психолог киңәшенчә, офиска кайту «корабльдән – балга» кебек булмасын.

– Ялдан кайтуның икенче көнендә үк эшкә чыгарга кирәкми, организм өчен бу стресс булмагае. Ялдан эшкә чыгарга өч көн кала кайтырга тырышыгыз. Гадәти тормыш ритмына кайту өчен кирәк ул көннәр, – ди Наилә Бәширова. – Елга бер бирелә торган ялны көтмичә, аны айга бер-ике тапкыр үзең дә оештыра аласың. Гаиләңне алып табигатькә чыгып керү өчен юллама да, кредит та алырга кирәкми. Гарәп Әмирлекләрендә, әйтик, җомга көнне гаиләләре белән табигатькә чыгып, зур эскәтерләрен җәеп, чәй эчеп утыралар. Шунда туганнарын да чакыралар. Бу инде туганнарның үзара ватсаптан смс алышуы гына түгел. Ә бездә туганнар белән берәр мәҗлес уңаеннан гына очрашу гадәте бар. Нишләп әле безгә дә моны тормышыбызга кертеп җибәрмәскә?! Кабатлап әйтергә туры килә инде: безгә ял итәргә өйрәнергә кирәк.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

БУ – КЫЗЫК!

Кытай халкы, эшкә урнашканнан соң, баштагы ун елда – 5, аннары – 10, егерме елдан 15 көн ял итә.

Малайзиядә эшли башлаган хезмәткәргә – 8 көн, ике ел стажы булганнарга – 12, биш елдан 16 көн ял бирәләр.

Америка Кушма Штатларында ялның күпме булуы закон белән билгеләнмәгән. Моны эш бирүче үзе хәл итә. Дәүләт бәйрәмнәрен кертеп, америкалылар уртача 28 көн ял итә.

Гарәп Әмирлекләрендә эшләүчегә хезмәт юлының башында – 10, ун елдан соң 15 көн ял бирелә.

Япониядә ял стажга карап бирелә, әмма эш яратучы япон халкы ялны сирәк ала. Һәр алтынчысы бөтенләй ялга чыкмый эшли.

Филиппинда яшәүчеләр елына – 5, Мексика халкы – 6, сингапурлылар 7 көн ял итә.

Бөтенроссия җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге уздырган сораштырулардан күренгәнчә, Россия халкының 47 проценты быел җәйне өйдә генә уздырырга планлаштыра. Кара диңгез курортларына һәр унынчы кеше бара, чит илгә сораштырылучыларның нибары 6 проценты гына китәчәк.

«Шәһри Казан»нан – алма бакчасы

«Шәһри Казан» газетасы һәм Югары Ослан районының Ямбулат авылындагы «Заря» питомнигыннан бүләккә алмагач үсентеләре алуның әллә ни кыенлыгы юк. Газетадагы анкетаны тутырып, 2017 елның II яртыеллыгына язылу турындагы квитанцияне редакциягә җибәрергә һәм жирәбә нәтиҗәләрен генә көтәргә кирәк. Үзегезгә ничек җайлы, шулай эшләгез, без аларны почта аша да, электрон адресыбызга да, «ватсап» аша да, социаль челтәрләрдәге төркемнәребездә дә кабул итәбез. Бүләк ике атна саен уйнатыла. Җирәбә уйнатуны видеога төшереп, **www.shahrikazan.com** сайтында урнаштырабыз.

Әйдәгез, алма бакчасында «Шәһри Казан» укыйк әле!

ИНДЕКСЛАР

П2430 – пәнҗешәмбе саны, ярты елга язылу бәясе – **450 сум.**

П2395 – атнага өч тапкыр: сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга көннәрендә чыга, ярты елга язылу бәясе – **930 сум.**

АНКЕТА

1. Исем-фамилия, адрес, телефон______________

____

2. Яшегез______________________

3. Шөгылегез____________________

4. «Шәһри Казан» газетасын кайчаннан бирле алдырасыз?______________

____

5. Газета белән беренче тапкыр ничек һәм кайда таныштыгыз?______________

____

6. Газетага ничек язылasыз:

почта бүлекчәсендә _____

хат ташучы өйгә килә _____

интернет аша _____

____

7. Газетаны кайсы битеннән укый башлыйсыз?

____

8. Сезне нинди эчтәлектәге язмалар җәлеп итә?

____

____

9. Газетада тагын нинди темаларның күтәрелүен телисез?______________

____

10. Газетаның миңа иң ошаган:______________

____

ошамаган яклары:______________

____

____

11. Тагын нинди газета-журналлар алдырасыз?

____

____

vk.com

Тол хатыннан ачык хат

«Ахырзаман алдыннан ирләр сугышсыз кырылыр», – дигән борынгылар. Әлеге сүзләргә инанырлык дәлилләр туып кына тора. Тормыш терәген югалтып, пар канатсыз калган олы йөрәкле ханымнарга теләктәшлек итеп, ярдәм кулы сузасы урында аяк чалып, нахакка гаепләүдән чирканмаучылар да җитәрлек.

Шундыйларның корбаны булып, сынмый-сыгылмый калган Зөләйха ханым:

– Бу хакта күптән язасым килеп йөри иде, – дип башлады сүзен. – Мин инде 20 еллык «стаж»ы булган тол хатын. Ирем йорт салып кергәннең икенче көнендә бакыйлыкка күчте. Йөрәк, диделәр. Хәсрәт тулы күңелем белән дүрт баламны кочаклап, 40 яшемдә япа-ялгыз калдым. Көне буе эштә, аннары йорт төзү белән мәшгуль, бернинди ял күрмәгән иремнең китеп баруы минем тормышны ике өлешкә бүлде: аның белән булган һәм ансыз көннәргә. Бер мәл тормыш туктагандай булды. Ул вакытта әти-әнием дә исән-сау иде, туганнарым да, дуслар да җитәрлек иде. Иремне соңгы юлга озатканда ярдәм дә итештеләр, әмма икенче көнне үк мин дөньядагы иң оятсыз, ирен сакламаган, аны вакытыннан алда гүргә керткән ялгыз хатынга әйләндем дә куйдым. Ятлар бер хәл, тик якыннар авызыннан да ишетү авыр булды. Иремнең үлемендә мин гаепле булганмын... Әлеге гаделсез тормыш сабагын татыган, минем кебек ялгыз калган хатын-кызлар бәлки минем ачык хатымны укып, юаныч табар, ә белер-белмәс нахакка гаепләүчеләрнең күңелендә бәлки рәхим-шәфкать уяныр, – диде ул, яшьләрен сөртеп...

«Хөрмәтле һәм гыйззәтле гаепитүчеләр! Мин дә, һәркем кебек, бәхетле булыр өчен туган идем. Үзем яраткан кеше белән гаилә корып, күп итеп бала үстереп, үзебез салган нигездә тигез, матур гомер итү иде хыялым... Авырлыклар белән булса да, хыяллар чынга аша сыман иде. Тик биш ел буе тиенен тиенгә җыеп, беркем ярдәменнән башка салып чыккан өйдә гөрләшеп, пар канатлы булып яшәргә насыйп булмады. 45 яшендә ирем китеп барды, ә мин гаепле булып калдым! Ни өчен дисезме? Ирем исән калып, мин үлмәгәнгә, мөгаен! И кешеләр, күз алдыгызга китерегез инде, мин киткән булсам, сезгә җиңелрәк булыр идеме? Ятим калган дүрт баланың башыннан сыйпап, мескен иргә җәлли-җәлли хатын эзләү сезгә, әлбәттә, күбрәк канәгатьләнү хисе китергән булыр иде... Тик нишләтәсең, тәкъдирдә шулай язылган булган. Әниле бала ятим булмый, диләр, димәк, Ходай миңа гомер биреп, балаларымны ятим итмәгән. Әтисез үсү җиңел булгандыр димим, тик балалар күңелендә әтиләре рухын сүндермичә, төрле хәлләр туганда: «Әтиегез болай әйткән булыр иде», – дип, аңа һәм үземә хыянәт итми яши белдем. Ячулар җибәреп, кияүгә чыгуымны сораучылар булмады түгел, булды, тик иремне алыштырырдай кешене эзләмәдем дә, кирәге дә юк иде. Чөнки үз балаларын үстерүдән баш тартучылар буарлык заманда, кеше баласына кемнең исе китсен.

Минем бар максатым – балаларны кеше итеп, аякка бастыру иде. Аллага шөкер, барысы да югары белем алып, дәрәҗәле урыннарда эшлиләр. Йөземә кызыллык китермәделәр, мөстәкыйль һәм үз максатларына ирешә алырлык, туган җанлы булып үстеләр. Балалар яхшы гына урнашып, тормышлар көйләнеп киткәч, туганлык хисләре уянган һәм элеккеге дуслыкларын исләренә төшерүчеләр дә пәйда булды. Әй җаныкайлар, безгә авыр чакта сез кайда идегез соң? Хөкүмәткә рәхмәт, балалар пенсиясен вакытында алып барып, ач булмадык. Тик ишле гаиләгә ярдәм булсын дип, ярдәм иткән кеше булмады. Без беркемгә дә кирәкле һәм кызыклы кешеләр түгел идек...

Тол хатын, яши белсә, ялгыз булмый... Чөнки аның ялгызлыкны уйлап елап ятарга вакыты да, хакы да юк. Өйдән-өйгә кереп моң-зар таратып, ашарыма ризыгым булмый, мескен хәлендә калган булсам, бәлки мине җәлләп, савап булсын дип, учыма сәдака салучылар булыр иде. Тик мин мескен булырга тырышмадым. Ә бу күпләрнең ачуын китерде. Ничек инде бетәшкән мескен хатынның кеше шикелле яшәргә хакы булсын?! Җәмәгать, минем дә бу дөньяда нәкъ пар канатлы кешеләр кебек үк хакларым бар икәнлеген онытмагыз!

Елап утырырга вакытым булмады дидем, ләкин тормышта йөрәкне нык әрнетә торган минутлар була. Балалар үз тиңнәрен табып гаилә кора башлагач, туйларында изге теләкләр теләгәндә ялгызлык, үзен нык сиздереп, бәгырьне телгәли. Шундый мизгелләрдә: «Эх, әтиләре исән булып әлеге матур вакытларны күреп, үзенең хәер-фатихасын бирсә иде!» – дип бәргәләнәсең...

Сүземне йомгаклап, минем хәлдә калган ялгызларга шуны әйтәсем килә: сынмагыз, сыгылмагыз, үзегезгә хыянәт итмәгез! Балалар өчен борчылмагыз, авырлык күреп үскән балалар, рәхәттә үскәннәргә караганда, күбрәк игелек күрсәтә. Газизләрегезне тормыштан һәм эштән тәм табарга өйрәтсәгез, бар да яхшы булачак. Гаепләүчеләргә игътибар итмәгез, һәркем үз каланчасыннан чыгып фикер йөртә, үртәлеп, юкка вакытыгызны һәм көчегезне сарыф итмәгез. Ә парлыларга шуны әйтер идем: булганның кадерен белегез. Ирле кеше Идел кичкән, дип юкка гына әйтмәгән халык.

Изге теләкләр белән, **Зөләйха апагыз.**

Итәк кенә димәгез

Элек-электән, хатын-кыз энергияне җирдән ала, дип санатаннар. Борынгыларның сүзләрен бүген галимнәр дә дәлилли. Озын итәк хатын-кыз гормоннары эшләп чыгарылуда ярдәм итә. Нәфис зат өчен энергиянең аска таба китүе мөһим, чөнки аның бала ялару һәм табу, хатын-кыз гормоннары эшләп чыгару органнары гәүдәсенең аскы өлешендә урнашкан. Шуны да истә тотарга кирәк: хатын-кыз гормоннары киму белән, аның сәламәтлеге дә какшый, матурлыгы да кими.

fonstola.ru

Озын итәк кигән хатын-кызга ир-атларның күбрәк игътибар иткәнен галимнәр дә исбатлаган.

«Бала таба алмаячак» дигән мөһер салынган хатын-кызларның, итәк кия башлаганнан соң, балага узу очраклары билгеле. Димәк, әлеге гап-гадәти киемнең әллә нинди могҗизага ия икәнлегенә ышанмас җирдән ышанырсың.

Җиргә кадәр тиеп торган озын итәк, читтән караганда, өчпочмакны хәтерләтә кебек. Әлеге «өчпочмак»ның зурлыгы итәк кыскарган саен кечерәя. Шуңа бәйле җирдән алынган энергия хисабына эшләнеп чыга торган хатын-кыз гормоннары күләме дә кими дигән сүз икән.

Чалбар кигән, авыр чемодан тартып баручы хатын-кыз белән итәк кигән һәм шундый ук чемодан тәгәрәтүче нәфис затка тиз генә ярдәм кирәк булды, ди. Ир-атлар, әлбәттә, итәк кигәненә ярдәмгә ашыгачак, ә ир-ат гормоннары бөркелеп торган гаярь хатын-кызга ярдәм итүче табылмаска да мөмкин.

Димәк, хөрмәтле хатын-кызлар, бүгеннән чалбарларны ташлыйбыз, итәк белән күлмәк кия башлыйбыз!

Хөрмәтле укучыларыбыз! Гаиләдәге катлаулы хәлләр яисә тормыштагы уйланмаган үзгәрешләр аркасында туган үзегезне борчыган сорауларыгыз булса, ике дә уйламый, «Ахирәт»кә дигән тамга белән, «Шәһри Казан»га юллагыз. Без сезне борчыган мәсьәләләргә белгечләр ярдәмендә җавап бирергә тырышырбыз. Шулай ук гыйбрәтле тарихлар язып җибәрсәгез дә, без бик шат булыр идек. Сездән хатлар көтеп, ихтирам белән, «Ахирәт» сәхифәсе.

norbekov.com

Хатын-кыз аны аңлау өчен түгел, ә яратылыр өчен туган.
Оскар Уайльд.

Көчсезлек белән коралланган хатын-кыздан да көчле нәфис зат булмый.
Иван Бунин.

Бары хатын-кыз гына вакытны туктатып торырга сәләтле.
Юзеф Булатович.

Тарих ир-атлар исемен генә хәтерендә калдырса да, тарихны тудыручылар – хатын-кызлар.
Генрих Һейне.

Сәхифәне **Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА** әзерләде.

БЕЗДӘ КУНАКТА – «ӘТИ ХАКЫ» БӘЙГЕСЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Әти хакы... Ике генә сүздән торган әлеге сүзтезмәгә никадәр мәгънә салынган. Монда әтиләрне зурлау да, аларга булган хөрмәт-ихтирам да, бетмәс-төкәнмәс мәхәббәт тә сыйган... Узган елның декабрендә «Шәһри Казан» газетасының, Татарстан Дәүләт Советы депутаты Ирек Салиховның «БлагоДарение» яшь буын һәм социаль инициативаларга теләктәшлек күрсәтү хәйрия фонды белән берлектә, «Әти хакы» бәйгесен оештырып җибәрүе дә юктан гына бар булмады.

Менә алар җиңүчеләр:
«Үрнәк ӘТИ» номинациясендә – Айсылу Нигъмәтҗанова (*Сарман районы, Юлтимер авылы*)

«Киң йөрәкле ӘТИ» номинациясендә – Латыйповлар-Миңнуллиннар гаиләсе (*Яшел Үзән районы, Норлат авылы*)

«Батыр ӘТИ» номинациясендә – Чулпан Гыйльманова (*Түбән Кама районы, Шәңгәлче авылы*)

Ә **махсус бүләккә** ия булган *Балтач районыннан* Эльвина Иванова мультиварка белән бүләкләнде. «Шәһри Казан» газетасының истәлекле бүләге исә Кукмарадан Рәсимә Минһаҗевага тапшырылды.

Зөһрә САДЫЙКОВА

– Мин үзем һәрвакыт «Әтиең нәрсә әйтер?» дигән сүзне ишетеп үстем, чөнки өч кыз бала тәрбияләнгән гаиләдә соңгы сүзне һәрвакыт ул әйтте. Әнинең әтигә булган хөрмәте безгә дә күчте. Бәйгегә килгәндә, әниләргә багышланган конкурслар һәрвакыт оештырылып килә, ә менә әтиләр бераз читтәрәк кала иде. Аларга да игътибар иттерәсебез килде. «БлагоДарение» фонды җитәкчелеге дә әлеге идеяне күтәреп алды, – диде газетабызның баш мөхәррире Гөлнара Сабирова.

Исегезгә төшерәбез, әти ролен күтәрүгә, үрнәк гаиләләрне барлауга юнәлтелгән бәйге быелның 31 мартына кадәр дәвам итте. Һәм шушы вакыт эчендә редакция почтасына 60тан артык язма килде. Аларның күпчелеге газета битләрендә дөнья күрде инде, ә калганнары, бәйге тәмамлануга карамастан, киләсе саннарда басылачак. Шушы көннәрдә исә редакциябездә, бәйгегә йомгак ясалып, җиңүчеләрне тәбрикләү тантанасы узды. Аларны фонд вәкилләре һәм газета хезмәткәрләре кергән жюри билгеләде. Конкурста өч номинациядә җиңү яулаган өч кешегә велосипедлар бүләк ителде.

– Бүген, кызганыч, гаиләдә, ни өчендер, әти сүзенең төшенчәсе саекланды. Әмма әлеге бәйге әтинең дә нәкъ әни кебек үк кирәклеген күрсәтте. Бер-беренә хөрмәт тулы гаиләдә үскән бала көчле дә, бәхетле дә була. Шуны кабат исбатлаганыгыз өчен рәхмәт сезгә, – дип мөрәҗәгать итте бәйге җиңүчеләренә Гөлнара Сабирова.

Җиңүчеләр һәм аларның гаиләләре белән бергә түгәрәк өстәл артында Татарстанның премьер-министры урынбасары, республиканың «Әтиләр берлеге» иҗтимагый оешмасы рәисе, бәйгенең жюри рәисе Васил Шәйхразиев, «БлагоДарение» яшь буын һәм социаль инициативаларга теләктәшлек күрсәтү хәйрия фонды президенты Фәрит Салихов һәм әлеге фондның директоры Рузилә Шәймәрданова, «Татарстан радиосы» дикторы, «Пар канатлар» тапшыруы алып баручысы Рәзин Нуруллин да утырды.

Васил Шәйхразиев, кунакка килгән балаларны, аларның әти-әниләрен җиңүләре белән тәбрикләп ихлас теләкләрен җиткергәннән соң, үз гаиләләре турында сөйләде:

– Әтием бакыйлыкка күчкәндә, миңа 19 яшь иде. Әни, 46 яшендә ялгызы калып, өч баланы аякка бастырды. Без дә бер-беребезгә ярдәм итешеп, һәрчак әни янында булдык. Кадерле кешебезгә инде 81 яшь. Бер яктан, аның шундый күркәм яшькә җитүе белән горурлансак, икенче яктан, әтинең безнең янybызда булмавына күңел сыкрый. Без һәрвакыт үрнәк гаиләләрне күрсәтергә, алар турында сөйләргә, язарга тиеш, – диде ул.

Фәрит Салихов та әлеге матур чараның бик кирәкле булуын билгеләп узды.

– «Шәһри Казан» газетасы бүгенге җәмгыятьтә әтиләрнең ролен күреп, аның абруен күтәрү юнәлешендә бәйге игълан иткәч, «БлагоДарение» фонды аларның башлангычын хуплап, чын күңелдән күтәреп алды, һәм безнең эшебез тиешле нәтиҗәсен бирде. Мин язмаларның барысын да бирелеп, күңелемә якын итеп укыдым. Аларның һәрберсендә кеше язмышы, йөрәк түреннән чыккан хисләр ята, – диде ул.

Рузилә Шәймәрданова әйтүенчә, 2015 елның 7 июлендә Дәүләт Советы депутаты Фәрит Салихов инициативасы белән оештырылган «БлагоДарение»да бик күп игелекле эшләр башкарылган.

– Әлеге бәйге өчен бүләк сайлаганда да озак уйлап тормадык, әтиле гаиләдә спортка да урын булырга тиеш дип, җиңүчеләргә велосипедлар тапшырырга булдык, – диде ул.

«Татарстан» радиосында 30 ел «Пар канатлар» тапшыруын алып баручы Рәзин Нуруллин фикеренчә, гаилә, әти-әни роле турындагы радио-телевидение тапшыруларының озын гомерле булмавының сәбәбе – халыкның күбрәк имин булмаган гаиләләр турындагы хәбәрләрне каравында. «Әмма «Пар канатлар» тапшыруында бервакытта да начар гаиләләр турында сөйләнмәде», – ди ул.

Җиңүчеләрне тәбрикләгәннән соң, гаилә кыйммәтләре турындагы сөйләшүләр түгәрәк өстәл артында дәвам итте.

«ИР-АТ ХАКЫН ӘНИЛӘРЕБЕЗ КЕБЕК ЗУРЛЫЙ БЕЛМИБЕЗ»

Рәйсә һәм Наил Латыйповлар-Миңнуллиннар гаиләсендә 12 бала тәрбияләнә. Шуларның икесе үзләренеке булса, калган унысын балалар йортыннан алганнар. «Кем кайда эшли, шуннан ташый инде», – дип көлә Рәйсә ханым, балалар йортында эшләвенә ишарәләп.

– Гаиләдә бала үзен кирәкле һәм кадерле итеп тойсын өчен, әти-әни нинди сыйфатларга ия булырга һәм балада нинди сыйфатлар тәрбияләргә тиеш?

Наил Латыйпов:

– Беренчедән, әти-әни баласын яратырга тиеш. Икенчедән, ир белән хатын арасында хөрмәт булганда, алар арасындагы мөнәсәбәтне бала да күреп үсә. Ул да якын кешеләренә охшарга тырыша. Мин, мәсәлән, тормыш иптәшемә бик рәхмәтле. Ул булмаса, үзем генә берни дә эшли алмас идем. Без икебез дә ишле гаиләдә туып-үстек, шуңа күрә үзебезнең дә күп бала булуын теләдек.

Искәндәр Нигъмәтҗанов, җиңүче Айсылу Нигъмәтҗанованың әтисе:

– Балаларга үрнәк булырга тырышабыз инде. Шуны аңлаганга, газетага да язма юллаганнардыр, күрәсең (*көлә*). Алар да йөзебезгә кызыллык китерми, ике кызыбыз да тырышып укыдылар. Үзебез гаиләдә өч малай һәм бер кыз үстек. Әни сүзеннән чыкмадык, эш белән тәрбияләндек.

ҖИҢҮЧЕЛӘРЕ

Васил Шәйхразиев:

– Авыл балалары әти-әниләре белән бергә эшләп үсә шул алар. Мин үзем дә алты яшьтән үк колхозда эшли башладым. Ай буе хезмәт итеп тә, нәрәтне япкач, колхозга бурычлы булып каласың әле. Әти: «Улым, ит ашама инде. Безнең бит колхозга әҗәтебез бар», – дип әйтә торган иде. Ит кыйммәт, ә ашыйсы килә... Авыл балалары һәрвакыт әти-әниләре янәшәсендә, чөнки алар бергә эшли, бергә ашый, бер-берләрен сүзсез дә аңлый.

Рәсимә Минһаҗева:

– Без тугыз балалы зур гаиләдә үстек. Әтиебезнең бакыйлыкка күчкәненә дүрт ел булса да, ул әле дә безнең яныбызда кебек, чөнки нинди генә эш-гамәлгә тотынсак та, «Әти нәрсә әйтер иде икән?» – дип уйлыйбыз. Әти 90 яшендә гүр иясе булды. «Шәһри Казан»да чыккан мәкаләне ул исән чагында ук язган идем. Үзенә укып күрсәткәч, бик канәгать калды. Һич ялган түгел, шушы язмам басылган газетаны мин кич буе кочаклап утырдым. Әти хакы... Әтиләрне зурлау... Алар бит шундый зур мәгънәгә ия сүзләр... Хәзер без ир-ат хакын әниләребез кебек зурлый белмибез. Әниебез затлы-зыялы, укымышлы иде, бөтен тормышны алып барды дисәң дә була, әмма ул гомер буе: «Әтиегез белән киңәшләшегез», – дип әйтеп килде. Ә әтиебез искиткеч тыйнак кеше булды. Ул депутат итеп сайлангач, стендка төшәргә кирәк булганда, ак күлмәген портфельгә салып китә иде, чөнки ыспай киенеп өйрәнмәгән. Гап-гади авыл кешеләренә хас булганча.

– Васил Гаязович, сезнең үзегезгә әтиегез тарафыннан нинди төп сыйфат салынды?

– Бу очракта мин кешелеклелекне күз алдында тотам. Балалар бит алар күп очракта әтидән күреп үсә, шуңа күрә әти һәрвакыт тугры, тормыш иптәшенең ярдәмчесе булырга тиеш. Хәләл җефетләребез без балачакта әни ролен башкаручылар бит инде алар. Ир-атның бәхете дә, бәхетсезлеге дә хатыныннан тора, диләр, тик ир дә үзен санларлык итеп яши белергә тиеш.

– Наил әфәнде, балаларыгыз сезнең турында «Безнең әти – супер!» дип язган. Шушы язманың язылу тарихын да беләсебез килә иде.

Рәйсә Миңнуллина:

– Аны балаларыбыз әтиләренә сиздермичә генә язды. Кечкенәләре башлаган, ә зурлары дәвам иткән. Ә «Безнең әти – супер!» дигәнне иң кечкенә улларыбыз уйлап тапкан. Гомумән, Яшел Үзән районында тәрбиягә бала алган ишле гаиләләр бик күп. Татарстанда без беренче урында торабыз. Бик тату яшибез, бергә эшлибез. Февральдә җыелыш ясап, «Әтиләр булдыра» дигән – тәрбиягә бала алган әтиләр җәмгыяten ачтык. Шунда әтиебезне совет рәисе итеп тәкъдим иттек. Ишле гаиләбездә «безнекеләр» һәм «читнекеләр» дигән караш юк. Алар барысы да безнеке. Бу көннәр безнең өчен бик сөенечле, чөнки район башлыгы Александр Тыгин 100 квадрат метр мәйданда янкорма төзергә ярдәм итәчәкләрен җиткерде. Моңа бик нык куандык. Киләчәктә барыбыз бергә утырып йөрердәй автобус булса да бик яхшы булыр иде. Балалар йортында эшләгәч, башка кешеләр, ятимнәр өчен күп сорарга туры килә. Ул вакытта кыенсынмыйм, ә менә үзең өчен сорарга бик авыр. Шушы мәсьәләнең дә уңай хәл ителәчәгенә ышанабыз.

Чулпан Гыйльманова:

– Әтиебез Хәмит безне гомер буе ялгызы тәрбияләде. 17 ел элек әниебез вафат булганда, миңа – 11, абыема 14 яшь иде. Әтиебез бик көчле кеше, чөнки аның батырлыгын бик сирәкләр генә булдыра ала. Башка гаилә корырга теләмәде, бу турыда ачыктан-ачык сөйләшү булмаса да, ул безне кыерсытуларыннан курыккандыр дип уйлыйм. Без аңа бик рәхмәтле. Узган ел ул инсульт кичерде. Хәзерге вакытта таяк белән йөри. Бәйге өчен язма әзерләгәндә дә бик яратып, җиңел яздым. Әтигә рәхмәт сүзләрен шулай газета аша җиткерәсем килде, чөнки мәктәптә, көллияттә укыганда, гел әни турында гына язарга кушалар иде. Ә миңа бу бик авыр бирелде. Укытучылар: «Әбиең турында яз алайса», – дип әйтсәләр дә, әти турында яздырган кеше булмады.

Җиңүчеләребез арасында 15 яшьлек Эльвина Иванова да бар иде. Мөлаем, ачык, һәр яктан сәләтле кызның әтисе аңа ике яшь чагында ук вафат булган.

– Әтиемне хәтерләмәсәм дә, аның белән бик горурланам. Үзе исән чагында күпме медальләр, күкрәк билгеләре алган ул. Узган ел, уйламаганда, аннан «бүләк» алдым. Чечняда вакытта әтием ничек яшәүләрен видеога төшергән һәм шул язманы, ниһаять, миңа күрсәттеләр. Әтием анда шулкадәр матур һәм шат! Ул, пеләш башын сыйпап: «Кызым, күрдеңме минем баштагы кояшны?» – дип көлгән, – ди Эльвина.

Яшүсмер хәзерге вакытта әбисе тәрбиясендә яши, чөнки дүрт ел элек каты авырудан әнисе дә вафат булган.

ЭШ КЕШЕСЕ

Автор фотосы

«Саулык булса, эшнең бер авырлыгы да юк»

Чувашстанның булдыклы татар егетләре турында белмәгән, ишетмәгән кеше юктыр сыман. Ит ризыклары базарын алар тота дияргә була. Бик күпләр, мал асраудан баш тартып: «Ит җитештереп, акча эшләп булмый», – дигән бер чорда, Урмай, Шыгырдан авыллары нәкъ менә ит җитештерүдә әйдәп баралар. Күптән түгел Чувашстан Республикасының Урмай авылында булып, уңышның серләренә төшенергә тырыштык.

Урмай авылы егете Илшат Пахалов, авыл башындагы иске ферманы арендага алып, ит өчен атлар, үгезләр үстерә. Иң элек Илшатның фамилиясенә игътибар иттем.

– Аптырыйсы түгел фамилиягә, без авыл егетләре, җир кешеләре. Фамилиябез дә «пахал», җир сөрдем сүзеннән алынган. Безнең бабай янына сезнең кебек кызыксынучылар килгәннәр дә сорашалар икән. Бабайның русчасы чамалы булган, нәрсә сорасалар да, «пахал да пахал» дип җавап биргән. Шуннан фамилиясен дә Пахалов дип язып куйганнар. Монысы нинди дәрәҗәдә дөрестер, әйтә алмыйм, ә менә гомер буе җир сөреп иген игүе хак. Аның малайлары да күп булган, димәк, җир кишәрлеге дә аз булмаган. Без дә менә җирдән аерылмадык. 111 гектар җиребез бар. Шуның 15 гектарында арпа, калганында люцерна үстерәбез, – диде Илшат.

– Илшат, соңгы елларда авыл хуҗалыгы тармагында булган үзгәрешләр сезнең якларга бик кагылмады шикелле. Мин әлеге очракта шәхси хуҗалыкларны күз уңында тотуым. Татарстанның кайбер авылларында терлек башы шактый кимеде.

– Сездә чәчүлек җирләре күп, колхозлар бик көчле иде. Халык та эшләгәне өчен бирелгән ашлык, печән хисабына терлек тотты. Яшерен-батырын түгел, ат арбасы төбенә салып алып кайтканы белән генә дә бер үгезен симертә иде инде ул. Үзгәрешләр башланып, колхозлар беткәч, авылларда халык аптырашта калды: кайдан азык юнәтергә? Җиңел эш түгел, бер сыер тотудан, мал симертүдән киткән кеше аңа бик сирәк әйләнеп кайта. Безнең авылларның исә халкы күп, җире аз, шуңа күрә азыкны ул гомер буе каяндыр тапкан, эзләгән. Үзгәрешләр дә безгә кагылмады диярлек, авыл халкы ничек яшәде, эшләде, шулай дәвам итә.

– Дәүләт ярдәмен алдыгызмы?

– Җитәкчеләр әйткәч, без кәгазьләр тутырып җибәреп карадык. Узмагансыз, диделәр. Бүтән аның артыннан йөрмим дә, кирәкми дә. Әйтәләр бит ризык әзерләгәндә, бик тәмле булган, үз суында гына кайнап пешкән дип. Монда да нәкъ шулай. Үз суында гына кайнап эшләсәң, бернинди кредит та кирәкми. Акчаң булса, төзисең, булмаса, бераз көтеп торасың.

– Ни өчен савым сыер асрамыйсыз? Ит сатып алучыны табу кыен түгелме?

– Сыер бер көнгә 70 кг тирес чыгара, диләр. Шуңа күрә кызыкмыйбыз. Симертү хайваннарын тере килеш кенә җибәрәбез. Үз кешеләре бар, килеп алып китәләр. Шулай ук дүрт-биш айлык үгезләрне, тайларны китереп саталар.

– Сезнең, казылык җитештермибез, дигәнегезгә ышанасы килми. Казылыкны монда һәркем әзерли кебек.

– Әйе инде, без дә казылык ясыйбыз, ләкин сату өчен түгел, үзебез, туганнарыбыз, дусларыбыз өчен. Кунак килсә, ничек без аны сыйламыйк, алдына казылык кисеп куймыйк ди. Ат итеннән генә түгел, без әле каздан да казылык әзерлибез. Узган ел күпләп каз алып үстергән идек, быел да, җәенә карап, уйларбыз әле. Бәлки көзгә таба бераз алырбыз да. Бер каздан дүрт-биш казылык чыга. Казылыкны аны кыш көне гаилә белән җыелып әзерлисең инде. Без иткә тоз, борыч, сарымсак, шикәр комы, бал гына кушабыз. Юк-бар тәмләткечләр кушып, тәмен алмыйбыз. Икенче үзенчәлеге – артык каты киптермибез. Казылык, әзер булганчы, өч урынга күчә, дүртенчесе – суыткыч.

Әле ярый мин дә кунак, дип сөенеп, Илшат Пахаловның казылыгыннан авыз итеп карадым. Бик күп төрлесен ашап караганым бар, яшермим, ә бу бөтенләй үзгә һәм бик сыйфатлы.

– Барысына да ничек өлгерәсез?

– Саулык булса, эшнең бер авырлыгы да юк аның! Аллаһы саулыктан, тынычлыктан аермасын.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА,
Чувашстан, Урмай.

Мәхәббәт аякка басарга ярдәм иткән

Рәхил абый Әхмәдуллин яныннан кешенең өзелгәне юк. Ул якын-тирәдә инде онытылып барган һөнәр – итеккә олтан салучы бердәнбер оста булараk билгеле. Тубыктан аягы булмаган Рәхил абый: «Аякка басарга мәхәббәт ярдәм итте», – ди.

Эльвира МОЗАФФАР,
Яшел Үзән, Бәчек

20 ЕЛДАН СОҢ ОЧРАШУ

Тәнзилә апа белән Рәхил абый Әхмәдуллиннарның мәхәббәт тарихы турында китап язарлык.

– Без Рәхил белән мәктәп яшеннән үк таныш. Мин Яшел Үзән районының Кече Өтәк авылыннан, еш кына җәйге каникулларга Бәчеккә кунакка кайтып йөри идем. Бер-беребезне бер күрүдән үк яраттык. Очраша башладык. Тик өйләнешер вакыт җиткәч, әни мине Рәхилгә бирмәде. Сәбәбен үләр алдыннан да әйтмәде. Аерылыштык. Мине башкага кияүгә бирделәр. Тора-бара Рәхил дә өйләнде. Безнең юллар шулай аерылды, – дип искә ала яшьлек елларын Тәнзилә апа.

Сөйгәне белән аерылышуны ул бик авыр кичерә. Поездадан да сикерә. Шөкер, исән кала. Күрешмәсәләр дә, бер-берсенә карата мәхәббәт хисләре сүрелми. Гаиләдә парлы ялгыз булып яшиләр. Мәхәббәтсез никахлар озын гомерле була алмый, күрәсең, икесе дә аерылыша.

Соңгы тапкыр күрешүдән соң 20 ел узгач, Тәнзилә апа белән Рәхил абыйны язмыш кабат Норлат авылы хастаханәсендә очраштыра. Ирнең хастаханәдә икәнен очраклы рәвештә белеп алган хатын, тәвәккәлләп, ул дәваланган палатага керә.

– Күзләребез очрашуга, икебездә дә хисләрнең сүрелмәвен аңладым. Без бер-беребезне һаман яратабыз икән бит. Бик озак сөйләшеп утырганнан соң, Аллаһыдан бирелгән бу мөмкинлекне кулдан ычкындырырга ярамый, дип, барысын да яңадан башларга булдык. Рәхил миңа: «Аякларым юк бит, Тәнзилә», – ди. «Аякларың чурт с ним, башка җирләрең исән булсын», – дидем дә көлдем генә, – дип сөйли Тәнзилә апа.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Ирнең аяклары тубыктан киселгән булуын, табибларның аның беркайчан да йөри алмаячагы турында әйткәннәрен белми әле ул чакта хатын.

Телефон аша аралашулар, хат алышулар... Менә йортка килен төшә.

– Ишек турыларына килеп җиттем, керергә оялам. Рәхил чыгып та алмый. Минем килгәнемне күреп, «Кер!» – дип кычкыра. «Ничек керим инде, чыгып ал», – дим. Ул аның саен: «Кер!» – ди. Үгетли торгач, өйләренә уздым. Карасам, ике аяк башы да юк. «Йөри алмыйм бит, Тәнзилә», – ди. Ни дияргә дә белмәдем, бакча башына чыгып еладым, үзенә берни сиздермәдем. Туганнарына: «Каршы булмасагыз, Рәхилне аякка бастырыр идем», – дидем. Шуннан бирле менә инде 17 ел без бергә, – дип сөйли Тәнзилә апа.

Җиңел булмый, әлбәттә, яраткан кешесен шундый хәлдә күреп, Тәнзилә апа да азаплана. Рәхил абый да сөйгәне каршында сер бирергә теләми. Мәхәббәт иң зур авырлыкларны да җиңәргә ярдәм итә. Тәнзилә апа ирен ләгәндә сөйрәп мунчага да алып бара, үлән сулары белән дә дәвалый, иңбашына таяндырып, урамнарга алып чыга. Башта аз-азлап йөриләр. Аннары чакрымнар уза башлыйлар. Табигатькә еш чыгалар. Ходайның рәхмәте, ир аякка баса.

Бүген тормышлары сокланырлык. Рәхил абыйның туганнарына да бик рәхмәтлеләр. Алар алып биргән йортта яшиләр. Тәрәзәсез, ишексез йортны төзекләндергәннәр, заманча җиһазлаганнар.

– 45 яшьлек юбилеема Рәхил өйгә газ кертте, тагын бер туган көнемә кер юу машинасы алып бирде, – дип сөенә Тәнзилә апа.

27 баш сарыклары бар, 30лап куян асрыйлар. «Суганны 17 түтәл утыртам», – ди Тәнзилә апа. Рәхил абый үзенә махсус аяк киеме җайлаштырган. Мичләр чыгара, эретеп ябыштыру белән шөгыльләнә, итеккә олтан сала, хәтта шабашкага да йөри.

– Хәрәкәт кирәк. Өзерне көтеп утырып кына тормыш бармый. Тәнзиләмә рәхмәт. Ул минем таянычым, коткаручым. Шөкер, тормыштан бик канәгать без, – ди Рәхил абый.

ИРЕҢ БЕЛӘН ТАТУ ЯШИСЕҢ КИЛСӘ

– Бер-береңне хөрмәт итеп яшәргә кирәк. Сүзгә килгәнсез икән, юл куя белегез. Ирең кычкырамы – чыгып кит, тавык куып кер, башка эш белән шөгыльлән. Каршы әйтмә, барыбер җиңә алмыйсың. Беркайчан да өметеңне өзмә, бер-береңне аңлап яшәгәндә, арада ярату булганда, иң зур авырлыкларны да җиңәргә була. Ирләрегезне яратып, хөрмәт итеп яшәгез, – ди Тәнзилә Әхмәдуллина.

Пенсиядәге фахишә монологы

ҮТЕП БАРЫШЛЫЙ

Равил САБЫР

– Мин нишләп йөримме? Менә син нишләп йөрисең ул?! Мин бу кунакханәдә администратор, минем монда утыруыма бер дә гаҗәпләнәсе юк. Нәрсә шулай итеп карап торасың? «Синме соң бу чыннан да, Диләрә?» – дип сорыйсың киләме? Әйе, мин. Университетның иң чибәр кызы, бөтен егетләрне акылдан яздырып йөргән Диләрә. Хәер, юк! Мин күптәннән башка Диләрә инде...

Юк, син хаклы түгел! Кадыйрның бер гаебе дә юк. Син нинди сигарет тартасың? Затлыны! Акчаң бар, димәк. Илле грамм коньяк та алып бирәсеңме соң?..

Хатын-кыз песи кебек гел дүрт тәпиенә төшә, диләр. Дөрес түгел! Мин дүрт тәпигә төшмәдем һәм гаепле дип үземне генә саныйм. Минем әле дә һәр көнем Кадыйр турында уйлап уза.

Әйе, син аңа чынлап та, шаярып та әйтә килдең: «Характерыңны үзгәртмәсәң, башың төрмәдән чыкмый синең», – дидең. Тик тышаулаган характер буламы? Әйе, аңа юлбашчы булу, үзен башкалардан өстен итеп хис итү, алар белән идарә итү бик ошый иде. Әйе, ул куркусыз, җилле, чая, тәвәккәл егет иде. Шул ук вакытта аның күп кенә гамәлләре акылсыз, дуамал иде шул. Сират күпере аша үткәндә, җәһәннәм уты өстеннән тартып куелган кылдан барганда рәхәт кенә чигәр кебек ул миңа...

Нәрсә? Сиңа чыннан да кызыкмы минем хәзер ничек яшәгәнем? Гаиләм-балаларым турында беләсең киләме? Юк шул сөйләр нәрсә! Ничектер бер мәгънәсез үтте дә китте гомер... Хәер, мин оялмыйм, мин – карт, пенсиядәге фахишә!

Теге вакыйгалардан соң ничектер акылдан язмаска кирәк иде бит, онытылыр өчен берәр юсыл табарга. Аракы эчә алмый идем ул чакта, наркотиклардан курыктым... Тик нидер эшләргә кирәк иде бит инде, үзеңне ни белән булса да мәшгуль итәргә. Ир-атларның ач карашларын тою да туйдырып бетерде, мин уңга-сулга типтерә башладым. Аннан соң бу шөгыль һөнәргә әйләнде... Хәзер картайдым, ир-атлар бик карамый башлады, пенсиягә чыктым инде. Бүгенге эшем – кунакханәгә урнашкан ирләргә кызлар тәкъдим итеп йөрим. Кирәкме соң сиңа да? Ну, ярар, үзең беләсеңдер...

Ә теге чакта, судтан соң, Кадыйр белән ике мәртәбә очраштык әле без төрмәдә. Ничек керттеләр, дип инде...

Суд булып, Кадыйрга унбиш ел биргәч, минем өчен тормыш туктады. Мин тулай торак бүлмәсендәге караватымда җиде көн тора алмыйча яттым. Алай да кызлар җилтерәтеп торгыздылар. Үзләре белән лекцияләргә алып бардылар, алып кайттылар, үзләре ашаганда утыртып ашаттылар. Ай ярым чамасы узгач, беркая да бармыйм дип карышсам да, авылга бер таныш кызларының туена алып кайтып киттеләр. Туй мәҗлесендә минем каршыга чәчләре ярты лаш чаларган абзый туры килде. Тора-бара аның Кадыйр утыра торган төрмәнең начальнигы булуы беленде. Кызлар барып ялварганнар моңа: «Диләрәне егете белән күрештерегез инде, зинһар!» – дип, ничектер күндергәннәр. Ул мине чакырып китерде дә: «Шимбә көнне килерсең, тик очрашу минем кабинетта, минем күз алдында була», – диде. Мин бардым, кердем моның кабинетына, Кадыйрны да шунда китерделәр...

Шул очрашудан соң минем хәлләрем тагын да авырайды. Кадыйр белән яңәшә булу, аның назларын тою теләге чыдый алмаслык итеп йөрәгемне кимерде. Аңа кадәр җаным гына сызласа, аннан соң бөтен тәнем авырта, ничектер бөтен нервыларым тартыла башлады. Рәхмәт төшкере, төрмә начальнигы кабинетында зонтигым онытылып калган икән. Шылтыраттым мин моңа. Килеп ал зонтигыңны, ди. Бардым, свидание сорадым 24 сәгатьлек. «Ярамый бит. Тик шулай да бер шартымны үтәсәң, булдырып булыр», – ди...

Свиданиеләр өчен махсус ясалган бүлмәдә Кадыйр белән без икәү бер тәүлек үткәрдек. Төрмәдә уздырылган булса да, ул минем гомеремдә иң бәхетле көн! Шул чакта әйтте ул: «Ышан миңа, Диләрә! Мин үтермәдем ул егетне. Башка кеше кылган җинаять өчен мин унбиш ел утырырга тиеш менә хәзер!» – диде. Ә мин ул әйтмәсә дә белә идем аның гаепле түгел икәнен...

Тик гафу итмәде ул мине... Нәрсә өчеме?

Төрмәдә Кадыйр белән уздырган 24 сәгатьтән соң озак кына хыялланып йөрдем әле мин. Аннан соң авырга узуымны белдем. Йөрәгем астында бала йөрткәндә, миннән дә бәхетле кеше юк иде бу дөньяда! Чөнки мин ул баланың Кадыйрның дәвамы булуына инанган идем. Бары тик тугач кына улымның атасы төрмә начальнигы икәнен аңладым – шул ук күзләр, шул ук куллар, хәтта тырнак формаларына кадәр бертөрле иде...

Нигә «иде» димме? Гомере булмады ул баланың. Аллаһы Тәгалә бик тиз үзенә алды аны. Интегеп яшәмәсен, дигәндер инде...

Ә ул тугач та, мин Кадыйрга гафу үтенеп хат яздым, безнең төрмәдә уздырган әкияти көнебез ни бәрабәренә алынганын аңлаттым. Шуның белән вәссәлам! Кадыйр, күрәсең, мине үз тормышыннан сызып ташлады...

Без аның белән бүтән очрашмадык. Дөрес, мин аның исәнлеге, ничек яшәве турында әледән-әле ишеткәләп тордым. Төрмәдән ул тугыз елдан чыкты. Аннан соң әле тагын ике мәртәбә утырды. Ул инде элеккеге Кадыйр түгел иде, тора-бара ата каракка әйләнгән дип ишеттем. Ә бер ел чамасы элек шундый хәбәр килеп ирешә: имеш, аны, төрмәдән чыгу белән, машинасы белән бергә шартлатканнар. Мин хәтта барып аның каберен үз күзләрем белән күреп тә кайттым, тик үлгәненә барыбер ышанмыйм! Ул исән! Кадыйр исән!..

Әй! Кая киттең син? Ник китәсең?!!

Ураза тоту өчен күңел белән ният кылу да җитә

Районнарда командировкаларда йөргәндә, газетадан булуыбызны белгәч, авыл халкы уразага кагылышлы сорауларны еш бирә. Укучыларыбыз аларны телефон аша да җиткереп тора. Үз чиратыбызда, сорауларга җаваплар эзләп, без «Казан нуры» мәчете имам хатибы Алмаз хәзрәт Мөхлисовка мөрәҗәгать иттек.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

– Алмаз хәзрәт, ураза тотмаучыны ифтар ашына чакырырга ярыймы?

– Ярый. Бүген ул ураза тотмаган булырга, ә иртәгә, ифтарда ишетеп кайткан вәгазьләр-нәсыйхәтләрдән соң, уразага керергә мөмкин. Аңа авыз ачу савабы ирешми, әлбәттә, әмма гыйбрәтләнсен, вәгазьләнсен өчен, мәҗлескә чакырырга була.

– Уразага керү ниятен ай буена әйтеп куярга рөхсәт ителәме?

– Рамазан алдыннан күпләр ай буена ураза тотарга күңеленнән ниятләп куя, тик һәр көнне әйтсәң, яхшырак.

– Сәхәрне ашаганнан соң, ният әйтергә онытканда нишләргә?

– Син күңелең белән уйлап куйган буласың, сәхәрне дә шул нияттән ашыйсың бит. Ураза тоту өчен күңел белән ният кылу да җитә.

– Төкерек йоту уразаны бозмыймы?

– Бозмый.

– Ни өчен авызны хөрмә белән ачабыз? Моның берәр хикмәте бармы?

– Авыз ачканда, Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.с.) иң беренче булып хөрмә кабып куйган. Хөрмә белән авыз ачу сөннәт гамәл. Аннары әлеге җимештә организм өчен файдалы матдәләр күп. Көне буе ач торганнан соң, ул ашказаны өчен дә файдалы.

– Хөрмә төшләрен ыргытырга ярамый диган сүз каян килеп чыккан ул?

– Хөрмә төшен ыргыту гөнаһ түгел. Элек аны тәсбих ясау өчен җыйганнар, ә ул хәзерге кебек кибетләрдә тулып та ятмаган, шуңа ыргытмаска тырышканнар.

– Кибетләрдә авыздагы исне бетерә торган сиптергеч препарат сатыла. Ураза вакытында, авыздан ис килмәсен өчен, шуны кулланырга ярыймы?

– Кулланмавың хәерле дип беләм.

– Уразада тәмәке тартырга ярамаганлыгын беләбез. Ураза тотучы тәмәке тартасы килү хисен басар өчен аны иснәсә ярыймы?

– Тәмәкене, гомумән, тартырга ярамый. Тәмәке иснәү уразаны бозмаса да, ул кеше киләчәктә, Ходай кушып, тартуын ташлар дип өметләнник.

– Рамазан аенда атналык укылырга тиешле догалар бар дип ишеттем. Алар нинди догалар?

– Нинди дога укысаң да яхшы. Аларны мөмкин кадәр күбрәк укырга тырышыгыз. Аллаһны күп итеп зекер итегез.

– Бала тугач, үз вакытында гакыйка корбаны чалынмаган очракта, аны хәзер ураза аенда чалырга, шул хөрмәткә аш үткәрергә ярыймы?

– Балага 15 яшь тулганчы, гакыйка корбаны чалырга була. Ураза аенда хайван чалу тыелмый, шуңа да шикләнмичә, гакыйка корбаны чалып, мәҗлес үткәрә аласыз.

– Ураза тоткан кешегә иннек сыларга ярыймы?

– Киңәш ителми.

– Авыз ачу вакыты җиткәч, башта ифтар ашаргамы, әллә ахшам намазын укыргамы?

– Икесе дә дөрес. Ә иң хәерлесе – хөрмә кабып куйганнан соң, намаз укып алу.

– Иртәнге намазны сәхәрне ашагач ук укырга ярыймы?

– Бу уңайдан дин галимнәре арасында ике төрле фикер бар. Кемдер ярый ди, кемдер сабыр итәргә куша. Мин үзем сәхәрдән соң ярты сәгать узгач укырга тырышам.

– Ураза авыр бирелмәсен өчен аны күбрәк йоклап уздыру дөресме?

– Рамазан ае ялкаулык ае түгел, мин уразада дип эшләмичә тик ятып булмый. Йоклап ятучыга да савап була, әмма кырда көне буе эшләп ураза тотучыга, аны йоклап уздыручыга караганда, савабы күбрәк языла. Кыенлыкны күбрәк күргән саен саваплырак, тик авырлык күрим әле дип, бу очракта хәлеңне махсус авырайтырга кирәкми.

– Фитыр сәдакасын кайчан бирә башларга була?

– Рамазан ае керүгә бирсәң дә була. Гаеткә кадәр биреп бетерергә кирәк.

– Аны кемнәргә бирергә?

– Мескеннәргә, фәкыйрьләргә, акчасыз калган юлчыларга, укырга теләгән, ләкин мөмкинлеге булмаган шәкертләргә, яңа гына ислам диненә килүчеләргә, зәкят өләшү белән шөгыльләнә торган оешмаларга бирә аласыз. Бу сәдаканы әти-әнисе баласына, оныгына яки, киресенчә, балалары аларга бирә алмый. Быел фитырның күләме – 100-600 сум.

– Авыр физик эш белән шөгыльләнүче ураза тотмыйча фидия сәдакасын гына бирә аламы?

– Юк, фидия аның өстеннән төшми. Хәзер мөмкинлеге булмаса, казага калдырып та тота ала.

ТӘРАВИХ НАМАЗЫН УКЫГЫЗ

Коръәндә Аллаһ әйтә: бөтен барлыкны җыям да гарасат мәйданы ясыйм, ди. Шушы мәйданда бөтенебез дә тезелеп басачакбыз да хөкемебезне кырык ел көтәчәкбез. Моннан берәү дә котылмый. Аллаһ кояшны түшәм биеклегенә төшереп куячак – баш миләре кайнап юкка чыгып, кире яңадан ясалып, янып, кырык ел буе басып торачакбыз. Хәзер менә шушы мәйданда кояш якынайтылгач – хөкем башлангач – җәннәттән рәхмәт фәрештәләре зиннәтле касәдә җәннәт ризыклары алып чыгып, бер төркем халыкны сыйлар ди. Бу сыйланган, ашаган, эчкән кешеләрнең кырык ел буена ашыйсылары, эчәсе килми икән. Болар кемнәр? Алар – Аллаһ ризалыгына өмет итеп, ураза тотучылар. Быел беренче елымны тотам, Аллаһ ризалыгын казану өчен бер генә атна булса да тотып карыйм диючеләр. Тагын бер төркем халык булачак, кояшның кызуыннан саклый торган махсус баш киеме алачаклар. Бөтен кешенең баш мие кояш кызуында кайнап чыкканда, бу кешеләрнең башында гаҗәеп бер баш киеме булачак. Болар — дөньяда тәһарәт алып яшәүчеләр. Тәһарәт алганда игътибар иткәнсездер, барыбыз да мәсих кылабыз. Шушы мәсих белән без үзебезгә гарасат мәйданында кияргә башлык тегәбез икән. Гарасат мәйданында аяклар сызламасын өчен нәрсә эшләргә кирәк? Менә шушы Рамазан аендагы тәравих намазлары аякларны гарасат мәйданында басып торуга әзерләү икән.

(tatar-islam.com)

РАМАЗАН ВӘГЪДӘЛӘРЕ

✓ **Рамазан аеның беренче ун көне – Аллаһ рәхмәтенә ия булу вакыты.**

✓ **Рамазан аеның икенче ун көне – гөнаһларның гафу ителү көннәре.**

✓ **Рамазан аеның өченче ун көне – тәмуг утыннан котылу көннәре.**

АШАП-ЭЧЕП БЕТЕРГӘЧ УКЫЛА ТОРГАН ДОГА

Әлхәмдүлилләәһилләзии әтыгәмәнии үә сәкаании үә җәгәләнии минәл мүслимиин.

(Мине ашаткан һәм эчерткән, мине мөселманнардан кылган Аллаһка барлык мактаулар булсын)

ЙОКЫДАН ТОРГАЧ УКЫЛА ТОРГАН ДОГА

Әлхәмдү лилләәһилләзии әхйәәнәә бәгдә мәә әмәәтәнәә үә иләйһиннүшүүр.

(Безне (вакытлыча) үлемнән яңадан терелткән Аллаһка мактау булсын. Без (барыбыз да) Аңа кайтачакбыз)

БАЛАЛАРЫБЫЗ ӨЧЕН УКЫЛА ТОРГАН ТЕЛӘК-ДОГА

Йа Раббым, балаларыбыз тәкъва, хәерле мөселманнардан, Үзең яраткан бәндәләрдән булсалар иде. Үзләре сау-сәламәт, күңелләре саф, йөзләре нурлы, диннәре дөрес, иманнары көчле булса иде. Йа Раббым, Үзеңә итагать итүчеләрдән, гыйбадәт кылучылардан, фарыз һәм сөннәт гамәлләрен үтәүчеләрдән, гыйбрәт алучылардан, канәгать булучылардан, нигъмәтләреңнең кадерен белүчеләрдән, күп зекер кылучылардан булсалар иде. Йа Раббым, аларга тәүфыйк, һидаять, зирәк акыл, гыйлем бир. Ислам динен куәтләүче, оятны белүче, әхлаклы, әдәпле, тәрбияле, намуслы, тырыш, максатчан, эчкерсез, юмарт, тыйнак, гадел, эшчән, уңган булсалар иде. Укуларында ачык зиһен, тел байлыгы, тел ачкычлары бир. Укытучыларына, остазларына, иптәшләренә, барча кешеләргә күркәм итеп, сөйкемле итеп күрсәт. Әчке күңелләре, тышкы кыяфәтләре һәрвакыт күркәм булса иде. Йа Раббым, әти-әниләрен, олыларны хөрмәт итеп, кечеләргә шәфкатьле, мәрхәмәтле, кешеләргә игелекле, ярдәмчел булсыннар. Чисталыкны, пакьлекне яратсыннар, сафлыкка омтылсыннар. Йа Раббым, кайгы-хәсрәт китермәсеннәр, күз яшьләре түктермәсеннәр. Балаларыбызга хәерле хәләл кәсепләр, хәләл сөт имгән, хәләл ризык белән ризыкланган иманлы хәерле парларын насыйп ит, салих вә тәкъва бәндәләреңә дус ит. Балаларыбыз безнең йөз аклыгы булса иде. Аларга хәерле озын гомер бир, Раббым. Аларның куанычларын күреп, шатлык-сөенечләр белән яшәргә насыйп ит. Амин.

12 ИЮНЬ– ДҮШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Җырлыйк әле!» (6+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Последний янычар» . Телесериал (12+)
10:00 «Үч». Телесериал (12+)
10:50 «Канун. Парламент Җәмгыять» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Легенда для оперши». Телесериал (16+)
13:00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа (12+)
14:00 «Закон. Парламент. Общество» (12+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Күчтәнәч» (0+)
15:15 «Без тарихта эзлебез» (6+)
15:40 Мультфильмы (0+)
16:00 «Чародей». Телесериал (6+)
17:00 «Үч». Телесериал (12+)
18:00 «Татарлар» (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Таяну ноктасы» (16+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында» (0+)
20:15 «Күчтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «Чёрное озеро» (16+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)
22:10 «Вечерняя игра» с Ольгой Павловой» (12+)
23:00 «Последний янычар». Телесериал (12+)
00:00 «Видеоспорт» (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Әдәби хәзинә» (12+)
08:30 «Яшәсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Онытa алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:05 «Кайнар хит» (12+)
11:00 «Татарлар» (12+)
11:30 «Белем дөньясы» (6+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Үч». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Без тарихта эзлебез» (0+)
14:00 «Кыргый табигать балалары». Документаль фильм (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Тамчы-шоу» (0+)
16:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Үч». Телесериал (12+)
19:10 «Халкым минем» (12+)
19:40 «Туган җир» (12+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Таяну ноктасы» (16+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Күчтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Онытa алмыйм». Ретро-концерт (0+)
22:45 «Йөрәктән – йөрәккә». Татарстанның халык рәссамы Абрек Абзгильдин турында телеочерк (6+)
23:35 «Яшәсен театр!» (0+)
00:00 «Яңалыклар» (12+)
00:15 «Белем дөньясы» (6+)
00:40 «Татарлар» (12+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
Вещание не предусмотрено

ПЕРВЫЙ
06.00 Новости.
06.10 Х/ф «А зори здесь тихие...» (12+)
10.00 Новости с субтитрами.
10.10 Х/ф «Весна на Заречной улице». Кино в цвете.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 Х/ф «Дорогой мой человек».
14.20 Х/ф «Экипаж». (12+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.10 Х/ф «Экипаж». (12+)
17.15 Премьера. «Лучше всех!» Рецепты воспитания».
18.20 Премьера. «Голос». 5 лет». Большой праздничный концерт в Кремле.
21.00 Время.
21.30 Д/ф Премьера. «Крым. Небо Родины». (12+)
23.15 «Что? Где? Когда?» Летняя серия игр.
00.25 Х/ф «Главный». (12+)

РОССИЯ 1
04.05 Х/ф «Кубанские казаки».
06.25 Х/ф «Наследница». (12+)
10.20 Т/с «София». (16+)
12.00 Москва. Кремль. Церемония вручения Государственных премий Российской Федерации.
13.00 Вести.
13.20 Т/с «София». (16+)
20.00 Вести.
21.10 Большой праздничный концерт ко Дню России. Трансляция с Красной площади.
23.15 Д/ф «Время России». (12+)
00.40 Х/ф «Территория». (16+)

13 ИЮНЬ– СИШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Музыкаль каймак» (12+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Последний янычар ». Телесериал (12+)
10:00 «Үч». Телесериал (12+)
10:50 «Туган җир» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Легенда для оперши». Телесериал (16+)
13:00 «Путь» (12+)
13:15 «Фолиант в столетнем переплете» (12+)
13:30 «Не от мира сего...» (12+)
13:45 «Я обнимаю глобус....»12+
14:00 «Если хочешь быть здоровым» (12+)
14:15 «Дорога без опасности» (12+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Күчтәнәч» (0+)
15:15 «Әдәби хәзинә» (12+)
15:40 Мультфильмы (0+)
16:00 «Чародей». Телесериал (6+)
17:00 «Үч». Телесериал (12+)
18:00 «Татарлар»12+
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Таяну ноктасы» (16+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында» (0+)
20:15 «Күчтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «Чёрное озеро» (16+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)
22:10 «Вечерняя игра» с Светланой Дорожко» (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Без тарихта эзлебез» (0+)
08:30 «Яшәсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Онытa алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:10 «Җырлыйк әле!» (6+)
11:05 «Татарлар» (12+)
11:30 «Халкым минем» (12+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Үч». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Әдәби хәзинә» (12+)
14:00 «Кыргый табигать балалары». Документаль фильм (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:45 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
16:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Үч». Телесериал (12+)
19:10 «Башваткыч» (6+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Таяну ноктасы» (16+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Күчтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Онытa алмыйм». Ретро-концерт (0+)
22:45 «Музыка елгасы». Ренат Еникеев (6+)
23:35 «Яшәсен театр!» (0+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
9.00 «Мир культуры»
9.40 «Психология и мы»
11.40 «Парламентские вести»
14.40 «Яңалыклар. Татарстан»
17.20, 20.45 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
09.20 Контрольная закупка.
09.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 Модный приговор.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Наедине со всеми». (16+)
13.20 «Время покажет». (16+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.00 «Мужское / Женское». (16+)
17.00 «Давай поженимся!» (16+)
18.00 Вечерние новости с субтитрами.
18.40 Прямой информационный канал «Первая Студия». (16+)
19.50 «Пусть говорят» с Андреем Малаховым. (16+)
21.00 Время.
21.35 Т/с «Мажор». (16+)
23.45 «Вечерний Ургант». (16+)

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России».
09.00 Вести.
09.15 «Утро России».
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
11.40 Вести. Местное время.
11.55 Т/с «Тайны следствия-9». (12+)
13.00 Т/с «Тайны следствия-9». (12+)
14.00 Вести.
14.40 Вести. Местное время.
14.55 Т/с «Тайны следствия-9». (12+)
16.00 Т/с «Тайны следствия-9». (12+)
17.00 Вести.
17.20 Вести. Местное время.
17.40 «Прямой эфир». (16+)
18.50 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 Т/с «Плюс любовь». (12+)
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». (12+)

14 ИЮНЬ– ЧӘРШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Җырлыйк әле!» (6+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Последний янычар». Телесериал (12+)
10:00 «Үч». Телесериал (12+)
10:50 «Ватандашлар» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Легенда для оперши». Телесериал (16+)
13:00 «Каравай» (6+)
13:30 Документальный фильм (12+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Күчтәнәч» (0+)
15:15 «Яшьләр тукталышы» (12+)
15:40 Мультфильмы (0+)
16:00 «Чародей. » Телесериал (6+)
17:00 «Үч». Телесериал (12+)
18:00 «Татарлар» (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Таяну ноктасы» (16+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында» (0+)
20:15 «Күчтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «Чёрное озеро» (16+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Әдәби хәзинә» (12+)
08:30 «Яшәсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Онытa алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:15 «Башваткыч» (6+)
11:05 «Татарлар» (12+)
11:30 «Туган җир» (12+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Үч». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Без тарихта эзлебез» (0+)
14:00 «Кыргый табигать балалары». Документаль фильм (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:45 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
16:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Үч». Телесериал (12+)
19:10 «Җырлыйк әле!» (6+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Таяну ноктасы» (16+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Күчтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Онытa алмыйм». Ретро-концерт (0+)
22:40 «Йөрәктән – йөрәккә». Миргазиян Юнысов турында телеочерк (6+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
11.40 «Вести – Татарстан»
14.40 «Яңалыклар. Татарстан»
17.20, 20.45 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
09.20 Контрольная закупка.
09.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 Модный приговор.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Наедине со всеми». (16+)
13.20 «Время покажет». (16+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.00 «Мужское / Женское». (16+)
17.00 «Давай поженимся!» (16+)
18.00 Вечерние новости с субтитрами.
18.40 Прямой информационный канал «Первая Студия». (16+)
19.50 «Пусть говорят» с Андреем Малаховым. (16+)
21.00 Время.
21.35 Т/с «Мажор». (16+)
23.45 «Вечерний Ургант». (16+)

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России».
09.00 Вести.
09.15 «Утро России».
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
11.40 Вести. Местное время.
11.55 Т/с «Тайны следствия-9». (12+)
13.00 Т/с «Тайны следствия-9». (12+)
14.00 Вести.
14.40 Вести. Местное время.
14.55 Т/с «Тайны следствия-9». (12+)
16.00 Т/с «Тайны следствия-9». (12+)
17.00 Вести.
17.20 Вести. Местное время.
17.40 «Прямой эфир». (16+)
18.50 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 Т/с «Плюс любовь». (12+)
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». (12+)

15 ИЮНЬ– ПӘНҖЕШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Башваткыч» (6+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Последний янычар». Телесериал (12+)
10:00 «Үч». Телесериал (12+)
10:50 «Белем дөньясы» (6+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Легенда для оперши». Телесериал (16+)
13:00 «Каравай» (6+)
13:30 «Фолиант в столетнем переплёте» (12+)
13:45 «Не от мира сего...» (12+)
14:00 Документальный фильм (12+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Күчтәнәч» (0+)
15:15 «Әдәби хәзинә» (12+)
15:40 Мультфильмы (0+)
16:00 «Чародей». Телесериал (6+)
17:00 «Үч». Телесериал (12+)
18:00 «Татарлар» (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Таяну ноктасы» (16+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында» (0+)
20:15 «Күчтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «Чёрное озеро» (16+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)
22:10 «Вечерняя игра» с Григорием Эйдиновым» (12+)
23:00 «Последний янычар». Телесериал (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Без тарихта эзлебез» (0+)
08:30 «Яшәсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Онытa алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:15 «Җир белән күк очрашканда». Татарстанның халык артисты Зөлфирә Зарипова турында телеочерк (6+)
11:05 «Татарлар» (12+)
11:30 «Яшьләр тукталышы» (12+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Үч». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Әдәби хәзинә» (12+)
14:00 «Кыргый табигать балалары». Документаль фильм (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:45 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
16:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Үч. Телесериал (12+)
19:10 «Ком сәгате» (12+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Таяну ноктасы» (16+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Күчтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Онытa алмыйм». Ретро-концерт (0+)
22:45 «Җир белән күк очрашканда». Татарстанның халык артисты Зөлфирә Зарипова турында телеочерк (6+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
9.00 «Музыкальная жизнь»
9.30 «Созидатель». Митрополит Казанский и Татарстанский Феофан

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
09.20 Контрольная закупка.
09.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 «Время покажет». (16+)
12.00 Прямая линия с Владимиром Путиным.
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.00 «Мужское / Женское». (16+)
17.00 «Давай поженимся!» (16+)
18.00 Вечерние новости с субтитрами.
18.40 Прямой информационный канал «Первая Студия». (16+)
19.50 «Пусть говорят» с Андреем Малаховым. (16+)
21.00 Время.
22.00 Т/с «Мажор». (16+)

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России».
09.00 Вести.
09.15 «Утро России».
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
12.00 Прямая линия с Владимиром Путиным.
15.00 Вести.
17.30 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
21.00 Т/с «Плюс любовь». (12+)
22.55 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». (12+)

16 ИЮНЬ– ҖОМГА

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Халкым минем...» (12+)
05:25 «Нәсыйхәт» (6+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник » (12+)
09:00 «Последний янычар». Телесериал (12+)
10:00 «Үч». Телесериал (12+)
10:50 «Нәсыйхәт» (6+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 Документальный фильм (12+)
13:00 «Башваткыч» (6+)
14:00 «Актуальный ислам» (6+)
14:15 «Все суры Корана» (6+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Күчтәнәч» (0+)
15:15 «Тамчы-шоу» (0+)
15:40 Мультфильмы (0+)
16:00 «Чародей». Телесериал (6+)
17:00 «Үч». Телесериал (12+)
18:00 «Родная земля» (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Белем дөньясы» (6+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында» (0+)
20:15 «Күчтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «ДК» (12+)
21:15 «Дорога без опасности» (12+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)
22:10 «Наша республика – наше дело» (12+)
23:10 «Последний янычар». Телесериал (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Нәсыйхәт» (6+)
08:30 «Яшәсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Музыкаль каймак» (12+)
10:10 «Ком сәгате» (12+)
11:05 «Татарлар» (12+)
11:30 «Кичке аш» (6+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Үч». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Нәсыйхәт» (6+)
14:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Күчтәнәч» (0+)
15:30 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:45 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
16:00 «Үткәннәр сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Үч». Телесериал (12+)
19:10 «Йөрәктән – йөрәккә». Фирдәвес Хәйруллина турында телеочерк (6+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Ватандашлар» (6+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Күчтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Музыкаль каймак» (12+)
22:45 «Йөрәктән – йөрәккә». Фирдәвес Хәйруллина турында телеочерк (6+)
23:35 «Яшәсен театр!» (0+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
9.00 «Рухи хәзинә»
9.30 «Бәхетем минем»
11.40 «Вести – Татарстан»
14.40 «Яңалыклар. Татарстан»
17.20 «Вести Приволжского федерального округа»
20.45 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
09.20 Контрольная закупка.
09.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 Модный приговор.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Наедине со всеми». (16+)
13.20 «Время покажет». (16+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.00 «Мужское / Женское». (16+)
17.00 Жди меня.
18.00 Вечерние новости с субтитрами.
18.45 «Человек и закон» с Алексеем Пимановым. (16+)
19.50 «Поле чудес». (16+)
21.00 Время.
21.30 Т/с «Мажор». (16+)
23.40 «Вечерний Ургант». (16+)
00.30 Т/с «Фарго». Новый сезон. «Городские пижоны». (18+)

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России».
09.00 Вести.
09.15 «Утро России».
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
11.40 Вести. Местное время.
11.55 Т/с «Тайны следствия-9». (12+)
13.00 Т/с «Тайны следствия-9». (12+)
14.00 Вести.
14.40 Вести. Местное время.
14.55 Т/с «Тайны следствия-9». (12+)
16.00 Т/с «Тайны следствия-9». (12+)
17.00 Вести.
17.20 Вести. Местное время.
17.40 «Прямой эфир». (16+)
18.50 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 Аншлаг и Компания. (16+)
23.35 Х/ф «Москва – Лопушки». (12+)
1.30 Х/ф «Моя любовь». (12+)

17 ИЮНЬ– ШИМБӘ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 Концерт (6+)
07:00 «Sиңа Миннән Sәлам» (6+)
09:30 «Автомобиль» (12+)
10:00 «Кайнар хит» (12+)
11:00 «Халкым минем...» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Каравай» (6+)
12:30 «Видеоспорт» (12+)
13:00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» (12+)
13:30 «80 яшьлек егет». Наил Дунаевның юбилей кичәсе (6+)
15:30 «Галимҗан Баруди». Документальный фильм (12+)
16:00 «Нәсыйхәт» (6+)
16:30 «Татарлар» (12+)
17:00 «Без тарихта эзлебез» (6+)
17:30 «Әдәби хәзинә» (12+)
18:00 «КВН РТ-2017» (12+)
19:00 Документальный фильм (12+)
19:30 Новости в субботу (12+)
20:00 «Адымнар» (12+)
20:30 «Җырлыйк әле!» (6+)
21:30 Новости в субботу (12+)
22:00 «КВН -2017. Первая лига». (12+)
23:45 «Клиника». Художественный фильм (16+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Сайра, сайра син, сандугач!». Татарстанның халык артисты Хәмдүнә Тимергалиеваның иҗат кичәсе (6+)
07:00 «Sиңа Миннән Sәлам» (6+)
09:30 «Шаян хәлләр» (16+)
10:00 «Кайнар хит» (12+)
11:00 «Башваткыч» (6+)
11:50 «Җырлыйк әле!» (6+)
12:45 «Җырларымны сезгә юлладым». Бәширә Насыйрова концерты (6+)
14:30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» (12+)
15:00 «Sиңа Миннән Sәлам» (6+)
17:30 «Нәсыйхәт» (6+)
18:00 «Сиңа гына...». ИлСаф концерты (6+)
18:55 «Кичке аш» (6+)
19:20 «Башваткыч» (6+)
20:10 «Җырлыйк әле!» (6+)
21:00 «Адымнар» (12+)
21:30 «Берәү гармун уйный». Кирам Сатиевның юбилей концерты (6+)
23:10 «Язмышлардан узмыш юк икән». Телефильм (12+)
02:40 «Татар халык җырлары»

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
8.00, 11.20 «Вести – Татарстан»
8.20 «Доброе утро, Татарстан!»

ПЕРВЫЙ
05.50 Х/ф «Один дома: Праздничное ограбление».
06.00 Новости.
06.10 Х/ф «Один дома: Праздничное ограбление».
07.40 Играй, гармонь любимая!
08.25 М/с «Смешарики. Новые приключения».
08.40 Умницы и умники. (12+)
09.45 Слово пастыря.
10.00 Новости с субтитрами.
10.15 Д/ф Премьера. «Николай Дроздов. Шесть мангустов, семь кобр и один полускорпион». (12+)
11.20 Смак. (12+)
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Идеальный ремонт».
13.10 «На 10 лет моложе». (16+)
14.00 Премьера. «Вокруг смеха».
15.45 «Угадай мелодию» . (12+)
16.30 «Кто хочет стать миллионером?» с Дмитрием Дибровым.
18.00 Вечерние новости с субтитрами.
18.15 «Точь-в-точь». (16+)
21.00 Время.
21.20 «Сегодня вечером» с Андреем Малаховым. (16+)
23.00 Х/ф Премьера. «Полный пансион». (16+)
00.30 Х/ф «Нецелованная». (16+)

РОССИЯ 1
5.15 Х/ф «Я или не я». (12+)
7.10 «Живые истории».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Россия. Местное время. (12+)
9.20 Сто к одному.
10.10 «Пятеро на одного».
11.00 Вести.
11.20 Вести. Местное время.
11.40 «Юмор! Юмор! Юмор!!!» (16+)
14.00 Вести.
14.20 Х/ф «Шанс». (12+)
18.00 Субботний вечер.
20.00 Вести в субботу.
21.00 Х/ф «Так поступает женщина». (12+)
01.00 Х/ф «Отец поневоле». (12+)

18 ИЮНЬ– ЯКШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 Концерт (6+)
08:00 «Адымнар» (12+)
08:30 Мультфильмы (0+)
09:00 «ДК» (12+)
09:15 Документальный фильм (12+)
09:45 «Тамчы-шоу» (0+)
10:15 «Яшьләр тукталышы» (12+)
10:45 «Музыкаль каймак» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Каравай» (6+)
12:30 Документальный фильм (12+)
13:00 «Закон. Парламент. Общество» (12+)
13:30 «Адымнар» (12+)
14:00 «Харис Нигъмәтҗанов моңнары». Концерт (6+)
15:00 «Ком сәгате» (12+)
16:00 «Җырлыйк әле!» (6+)
17:00 «Видеоспорт» (12+)
17:30 «Әдәби хәзинә» (12+)
18:00 «Башваткыч» (6+)
19:00 Телефильм (12+)
19:30 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа (12+)
20:30 Концерт (6+)
21:30 «Кичке аш» (6+)
22:00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Бәйрәм бүген!» «Казан егетләре» төркеме концерты (6+)
08:05 «Җиде язмыш». Фирүзә Сибгатуллина концерты (6+)
09:25 «Яшьләр тукталышы» (12+)
09:55 «Тамчы-шоу» (0+)
10:20 «Поем и учим татарский язык» (0+)
10:30 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
11:00 «Белем дөньясы» (6+)
11:30 «Халкым минем» (12+)
12:00 «Татар халык җырлары « (0+)
12:30 «Татарлар» (12+)
13:00 «Нәсыйхәт» (6+)
13:30 «Узып барышлый». Гөлнара Сабирова җырларыннан концерт (6+)
15:40 «Йөрәктән – йөрәккә» (12+)
16:30 «Музыкаль каймак» (12+)
17:20 «Әдәби хәзинә» (6+)
17:50 «Без тарихта эзлебез» (0+)
18:20 «Дөньядан туймыйк әле». Раяз Фасыйхов концерты (6+)
19:10 «Ком сәгате» (12+)
20:05 «Егет чак, җырлар чак». Татарстанның атказанган артисты Рөстәм Закировның юбилей кичәсе (6+)
22:05 «Сугышчан әтәч». Телефильм (12+)
23:20 «Халкым минем» (12+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
10.20 «Вести – Татарстан. События недели»

ПЕРВЫЙ
06.00 Новости.
06.10 Х/ф «2 билета на дневной сеанс».
08.05 М/с «Смешарики. Пин-код».
08.25 «Часовой». (12+)
08.55 «Здоровье». (16+)
10.00 Новости с субтитрами.
10.15 «Непутевые заметки» с Дмитрием Крыловым. (12+)
10.35 «Пока все дома».
11.25 Фазенда.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Идеальный ремонт».
13.10 Д/ф «Теория заговора». (16+)
14.10 Д/с «Страна Советов. Забытые вожди». (16+)
16.20 «Призвание». Премия лучшим врачам России.
18.20 «Аффтар жжот». (16+)
19.25 Премьера. «Лучше всех!»
21.00 Воскресное «Время».
22.30 «Что? Где? Когда?» Летняя серия игр.

РОССИЯ 1
05.00 Х/ф «Я или не я». (12+)
07.00 Мульт-утро.
07.30 «Сам себе режиссёр».
08.20 «Смехопанорама» Евгения Петросяна.
08.50 Утренняя почта.
09.30 Сто к одному.
10.20 Местное время. Вести-Москва. Неделя в городе.
11.00 Вести.
11.20 Смеяться разрешается.
13.10 «Семейный альбом». (12+)
14.00 Вести.
14.20 Х/ф «Райский уголок». (12+)
16.15 Х/ф «Мирт обыкновенный». (12+)
20.00 Вести недели.
22.00 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». (12+)

Первый, Россия1 каналларының программасы «Сервис-ТВ» АҖдан алынды

«ТАТАРСТАН» радиосы

12 ИЮНЬ – ДҮШӘМБЕ

РОССИЯ КӨНЕ

10.10 «Туган илем – газиз җирем». Әдәби-музыкаль композиция
10.55,13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.00-12.10,13.00-13.10,14.00 Трансляция радио России
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында».
13.10 Россия һәм Татарстан сәнгать осталары концерты
13.50 Новости. Спецвыпуск

13 ИЮНЬ – СИШӘМБЕ

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий
6.04 «Актуальное интервью»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35,10.00,13.10,18.10 Яңалыклар. Новости
6.50,7.50,10.55,13.55,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Диалог в прямом эфире
8.00-10.00,11.00-12.10,13.00-13.10,14.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.10 «Депутат каналы»
12.10 «Татарстан дулкынында»
13.20 Концерт
18.25 Ренат Еникеев әсәрләре

14 ИЮНЬ – ЧӘРШӘМБЕ

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы
6.04 «Нефть чыккан якларда»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35,10.00,13.10,18.10 Яңалыклар. Новости
6.50,7.50,10.55,13.55,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-10.00,11.00-12.10,13.00-13.10,14.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.10 «Актуальное интервью»
10.35 «Старт»
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.20 «Яшьлек аланы»
18.25 Уралда яшәүче милләттәшләребез Шәүкәт Әмиров (балалайка), Хәйдәр Гыйльфанов (җыр) концерты

15 ИЮНЬ – ПӘНҖЕШӘМБЕ

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий
6.04 «Перекресток»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35,10.00,13.10,18.10 Яңалыклар. Новости
6.50,7.50,13.55,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Диалог в прямом эфире
8.00-10.00,11.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.10 «Доброе братство лучше богатства» (на удмуртском языке)
10.35 «Время молодых»
12.00 «ПРЯМАЯ ЛИНИЯ С ВЛАДИМИРОМ ПУТИНЫМ»
18.25 «Тормыш түгел алсу алма...» Әхмәт Гадел әсәрләре буенча әдәби-музыкаль композиция

16 ИЮНЬ – ҖОМГА

6.00-8.00 «Иртәнге нур»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35,10.00,13.10,18.10 Яңалыклар.
6.50,7.50,13.55,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-10.00,11.00-12.10,13.00-13.10,14.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.10 «Вдохновенья миг»
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.20 Концерт
18.25 Мәсгудә Шәмсетдинова. «Рамазан». Музыкаль-хореографик фантазия

17 ИЮНЬ – ШИМБӘ

10.10 «Табигать дуслары»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55,13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.00-12.10,13.00-13.10,14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында».
13.10 Татар халык көйләре
15.10 Кыска хикәяләр. Зәки Зәйнуллин әсәрләре. 2нче өлеш

18 ИЮНЬ – ЯКШӘМБЕ

8.00-9.00 «Между Волгой и Уралом». Объединенный радиожурнал семи республик
9.00-10.10, 11.00-12.10, 13.00-13.10, 14.00-15.10,16.00-16.10, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий
10.55,13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.10 Ял концерты
15.10, 16.10 «Пар канатлар»

ЯЛ ПОЧМАГЫ

Аермалар тап

СКАНВОРД



Фаил Гаязов төзеде

Горизонталь буенча: Хәйруллина, тарантас, уку, Адлер, роза, Аза, «ДДТ», Яна, Алина, Арал, ти, трасса, Атами, әләм, мата, абак, Әюп, ми, капа, ураган, ара, ут, Денис, па, аел, Ка, НЛО, тотка, ук, ачы, Апиа, Рәшит, нарасый, стикер.
Вертикаль буенча: хулиган, кулинар, налог, Уганда, Азамат, имән, Лолита, алтын, рампа, Нара, ат, ректор, Лайма, ак, Уфа, АТС, ятим, «УАЗ», тур, ни, акт, тай, ода, та, ян, трап, Луис, «Аватар», адвокат, аша, Бин, Спа, Сафина, каскадёр.

ИКЕ ХАТЫН

Озаграк күрешми торган ике ахирәт очрашса, исәнлек-саулык сорашкач, сүз, гадәттә, ирләргә барып төртелә бит инде. Бу юлы да шулай.

– И, бер юне дә булмады инде бу ир дигән нәрсәнең, – озак еллар буе гаиләле булып яшәгән ханым шулайрак дип башлый да, ашыкмыйча гына тәмләп хурлагач, беркадәр күңеле булып, ахирәтенә төбәлә. – Менә син ялгыз башың, ә үзең миннән күпкә бәхетлерәк. Колагыңда алтын алка, өстеңдә затлы тун. Машинаң бар, фатирыңа ремонт ясаткансың...

Озак еллар буе ялгыз яшәгән ахирәте аны чын күңелдән кызганып тыңлап тора. Ара-тирә гаҗәпләнүен белдереп, тел шартлатып ала. Шулай да үзенең шатлыгы белән бүлешми түзә алмый.

– Ни бит, мин дә ул кадәр ялгыз түгел бит хәзер... – ахирәтенең гаҗәпләнүен күреп бераз тынып тора да дәвам итә: – Берничә ел инде... Бер кешем бар бит... Нигә әйтмәдең дип... Үзең соң?! Законлы ирең белән дә бер тапкыр очраштырганың юк бит.

– Соң, аның кешегә күрсәтер җире бармыни?! – дип кул селти тегесе.

– Минекенең бар. Тик четереклерәк нәрсә... Кычкырып йөри торган нәрсә түгел бит, малай, ни бит... Хатыны бар аның, кыскасы. Болай хурлавын хурламый, аерылырга да җыенмый бугай. Миңа анысы бик мөһим дә түгел, иң мөһиме – ул мине дә ярата. Минем өчен дә өзелеп тора.

Шуннан бу бик ашыкмыйча гына, тәмләп кенә үзенең сөяркәсен мактый башлый. Бу тиклем мактагач, ахирәтенең дә кызыксынуы арта һәм ул танышу теләген белдерә:

– Һич югы синекенә карап сокланыйм әле бер, таныштыр әле.

– Яхшы, – ди ахирәте. – Ул тиздән шушы тирәдән узып китәргә тиеш.

Көтәләр. Ир боларны искә алмыйча узып китә. Аны күрү белән, гомер буе гаилә тормышында яшәгән ханым кычкырып җибәрә:

– Шушымы сөяркәң?! Кит аннан! Бу бит минем ир...

Ике ахирәт шул арада көндәшкә әверелә. Ләкин әле көнләшүдән бигрәк, гаҗәпләнү өстенлек итә.

– Ахмак бит ул. Үзе саран, үзе икейөзле. Белмим, нәрсәсенә исең киткәндер инде, – ди хатыны.

– Юк, син ялгышасың, – дип каршы төшә сөяркәсе, – шундый кыю, зирәк кеше. Саран да түгел ул. Менә алтын алкаларым, йөзегем, туным, машинам.

– Кит инде, юкны сөйләмә. Бәйрәмдә чәчәк тә күтәреп кайта белми бит ул, бичара. Хәтта хезмәт хакының да яртысын гына бирә.

– Юк ла инде, – ди сөяркәсе, – акыл иясе ул. Аралашу, сөйләшү рәхәт аның белән. Барысын аңлап тора, бөтен эч серләреңне чишәргә була. Аны тыңласаң, яңа дөньялар ачкан кебек буласың.

– Сөйләп торган буласың тагын... – дип мәсхәрәле елмая хатын. – Сүз рәте беләмени ул?! Һәрвакыт ниндидер эчпошыргыч нәрсә турында мыгырдый – тыңларлык та түгел. Ә үзе шундый булдыксыз. Беркайчан мине яклашу турында уйламас. Хәтта ярты тәңкә калсан да килеп каршы алмас. Хулиганнар өзгәләп китсә дә, аңа барыбер. Ә өйдәге эш турында әйтмим дә инде мин. Чүкеч тотмаганына гына да биш быltыр.

– Алай түгел бит, – дип елмая сөяркә. – Миңа килсә, ул бер генә дә тик тора белми. Кайда нәрсәне төзәтәсе бар, шундук эшләп куя. Белмәгән эше юк үзенең. Нәрсәгә тотынса, шул көлеп тора. Бигрәк уңган ир инде!

Хатыны бераз гаҗәпләнеп карап тора да башын чайкап куя:

– Карале, син мине үртәр өчен юри шулай сөйләнәсең бугай ул.

– Әле өч көн элек кенә миңа бәйләнеп маташкан егетнең арт сабагын укытты. Көчкә качып котылды теге бахыр. Әйтеп торам бит, ул шундый кыю йөрәкле, юмарт күңелле, акыллы һәм кешелекле.

– Җанымны үртәп торма әле, – дип кул селти хатыны. – Инде ун елдан артык бергә яшим бит, аны миннән дә әйбәтрәк белгән кеше юк. Беткәнбаш инде шунда. Исәпкә бар, санга юк. Нәрсәсенә исең китәдер. Ир кеше буларак та аллә ни гайрәте юк бит, Ходаем. Атнага бер исенә төшсә ярый инде.

– О, бик хаталанасың, – сөяркәнең тавышында татлы газап чалымнары яңгырап китә, – бик ялгышасың син...

Шул рәвешле, ике хатын ике төрле сөйли, ике хатын ике ирне күрә. Ә ир – берәү генә. Могҗизалар күп инде бу дөньяда...

Марат КӘБИРОВ.

Туган җир

Иң матур як җирдә бер генә,
Һәр тарафта чәчәк-гөл генә,
Урманнарын, болын-кырларын,
Тал-тирәкле чишмә буйларын
Туплаган бит барысын үзенә.
Иң матур як –
Туган җир генә!

Иң серле як җирдә бер генә,
Кайтавазың килер – көл генә.
Урманнарның сихри моңнарын,
Чишмәләрнең шаулап җырлавын
Туплаган бит барысын үзенә.
Иң серле як –
Туган җир генә!

Иң тыныч як җирдә бер генә.
Кайтыр идем сиңа гел генә.
Басудагы туфрак исләрен,
Табигатьнең чуар төсләрен
Туплаган бит барысын үзенә.
Иң тыныч як –
Туган җир генә!
Иң гүзәл як –
Туган җир генә!
Ул һәркемнең була бер генә!

Гөлзилә ГАФУРОВА.

ТАШКА БАСКАН

✓ Явызның ялгышуы – аның яхшылыгы.

* * *

✓ Эрос булган җирдә вирус була.

* * *

✓ Әгәр язучыны укымыйлар икән, бу әле ул классик дигән сүз түгел.

* * *

✓ Җан теләгәнне эшләргә тән комачаулый.

* * *

✓ Пенсияне арттыра алмаган дәүләт пенсия яшен арттырырга мәҗбүр була.

* * *

✓ Хыянәт итмәгән чакларында ул һәрвакыт тугры иде.

* * *

✓ Кешегә баш эшләр өчен бирелмәгән.

* * *

✓ Бөек һәм мәгърур телегезгә тилчә чыксын.

* * *

✓ Китапның калынлыгы аны укучылардан яхшы саклый иде.

* * *

✓ Бүрене аяклары туйдыра. Дөрес, гел үзенекеләр түгел.

* * *

✓ Матур дөреслекне дуслар әйтә, ачы хакыйкатьне – дошман.

* * *

✓ Сирәк кулланылган дуслар яхшы саклана.

* * *

✓ Тәмле нәрсә тешләнгән була.

4 мәзәк

Пассажир:

– Машинистка, поездны бераз акрынрак алып бар, дип әйтә алмассызмы?

Проводник:

– Нишләп?

– Минем малай юл буендагы баганаларны санап бетерергә өлгерми.

* * *

– Әлү!

– Әлү!

– Исәнмесез!

– Исәнмесез!

– Ничек хәлләр?

– Искитмәле!!!

– Ой, гафу итегез, мин икенче җиргә эләктем бугай...

* * *

Генетиклар съездында американ:

– Без сыер белән тавыкны кушылдырдык. Хәзер берьюлы сөт, йомырка һәм ит алабыз.

Француз:

– Без бал кортын чебен белән кушылдырдык. Хәзер яңа бөҗәк юынтык чокырларыннан бал җыеп кайта.

Урыс:

– Ә без карбызны таракан белән кушылдырдык. Карбызны кисеп җибәрүгә була – орлыклары шунда ук як-якка сибелә.

* * *

Сөйгәнне ташлап киткән крокодил үз-үзенә кул салырга карар кыла. Ул телефон будкасына керә һәм номер җыя:

– Әлү! Бу күн-галантерея әйберләре фабрикасымы?

«ШӘҺРИ КАЗАН» – СИНЕҢ ӨЧЕН, СИНЕҢ ТУРЫНДА 8 (917) 851-69-62

Шәһри КАЗАН

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)

www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+
Сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 5955
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 722. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр - сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы